# ӨЙГӘ ТАБА

Бу китап, Ал маниягә әсир төшкәч,
Төркиягә күңелле гаскәр булып китеп,
Төркияне саклар өчен җәбһәдә шәһит
булган йөзләрчә Идел-Урал егетләренең
газиз рухларына багышланадыр.

Төн соң булса да, полковник Тимергалиев һаман йоклый алмады. Ул, киемнәрен чишенмәенчә генә, гаскәрчә ятып карады, берничә мәртәбә күзен йомып, үзен-үзе йоклады кебек иттерер өчен гырылдап та алды, ләкин баш эчендәге уйлар, дәртләр берсе артыннан берсе йөгерде, берсенә-берсе кушылып икеләнде, өчләнде, матур, ямьсез төсләр алды. Ул тормады, кайнады. Аның тишек-тошыкларыннан уй ташыды, фикер акты. Баш дулаган тегермән кебек туктамады, әйләнде-әйләнде, яңы фикерләрне, яңы уйларны он ясамакчы булды. Кирәкмәгәннәрен «пуф» иттереп очырмакчы булды. Шуңарга әллә кайдан килә торган җан сыкравы, күңел әрнүе катышты, сәбәпсез эч пошуы аны басты. Ул «уф» дип сулап күзен ачты. Аның күзе кечкенә генә өйдә йөгерде. Аның диварына асылган харита, аның өстендәге зур-кечкенә шәһәрләрнең ишарәтләренең күзен акайткан кебек каравы аны әллә ник калтыратып җибәрде. Тәненнән әллә нинди бер суык үтте. Тулган айның яктысында гына ул андагы шәһәрләрнең, елгаларның исемен күрмәсә дә, күңеленнән дә ул хаританы белгәнгә, ул анда Багдадны, Мосулны, Эрзерумны, Трабзонны күрде, Морад чаен, Форатны, Дәҗләне, Ван күлен аерды. Аңарга кагылган кечкенә байраклардан шундагы гаскәрләрнең урыннарын, хәрәкәтләрен күргән кебек, шундагы туп тавышларын, бала еглауларын, аналар аһларын ишеткән кебек булды. Тагы күңелендәге тирән бер йире сыкрады. Бәгыре ыңрады, ул гаскәрчә иттереп сикереп торды. Башындагы авыр уйларны бетерер өчен шарт-шорт иттереп тәрәзә янына килеп басты.

Аның нурына коенган мәчетнең туп берлә тишелгән михраб урыны сукыр кешенең күзе кебек полковникка карады. Аның яртылай өзелеп төшкән манарасы кулы кешенең кулсыз җиңе кебек селкенә, саллана кебек, моңар йодрык күрсәтә кебек булды. Аның артындагы җимерек, ватык төрек өйләре, төрек йортлары - җәрәхәтләреннән еглый, сыкрый кебек тоелды. Ул уйга чумды. Бәлки бу манара, йөзләрчә еллар моңлы тавышын тирә-юньгә тараткан манара минем әмерем берлә атылган, туп берлә киселгәндер? Бәлки бу михраб, ничә йөз еллар кешеләргә күңел тынычлыгы, рәхәте биргән михраб минем гаскәремнең көче берлә җимерелгәндер? Бу өйләр, бу йортлар, эчләреңдәге бәхетле гаилә учаклары минем гаскәрем тарафыннан сүндерелгәндер? Шул йөзләр, меңнәр гөнаһсыз ханыннар, балалар минем тарафымнан үтерелгәндер?..Ул куркып китте. Кара фикерләрен куар өчен ул ут алды. Өстәл өстенә ташланган кәгазьләр, хариталар арасындагы кызының соңгы хатына күзе төште. Тагы күңеленең бик тирән бер йире әрнеп китте. Өйдә һава җитми кебек булды. Сулыш тарайды кебек тоелды. Ул тиз генә тышка чыкты.

Суык һава аны кочаклап алып коендырды. Моңланып килә торган ай нуры аны сөйде, акрын гына исә торган салкын йил аны юды. Аның күңеле ачылып китте. Ул озын бушлык буенда акрын гына йөренә башлады. Тирән төн булганга, бөтен исән өйләрдә, бөтен казылган йир астларында гаскәрләр тирән йокыда иделәр. Кош-корт, хайван бетерелгәнгә, бөтен җимерек авыл каберстан кебек тыныч иде, моң иде. Шул тынычлык полковник күңеден тынычландыра, шул моңлык арыган тәнен хәл җыйдыра иде... Ул бер әйләнде, ике әйләнде. Авыр фикерләрдән, мәгънәсез эч пошулардан бушанды кебек булды. Өйгә таба борылды. Еракта гына бер туп тавышы гөрләп китте, аңарга җавап кебек икенче тупмы күкрәде, ерактагы тауларда гынамы тавыш уйнап кайтгы. Полковник күзен текте. «Безнекеләр дошман берлә атышалар»,— димәкче булды. Ләкин «безнекеләр кем соң? Дошман кем соң?» — дигән сөаль килеп басты. Тагы башын чуалтты: «Чын, без кем?

Дошман кем? Мин, полковник Тимергалиев, кем?!!»

Ерактан килгән моңлы туп тавышы бунысы сөаленә жавап кебек булды: «Төрекләр аттылар»,— диде... Тагы күзе мәчеткә, манарага, аның янындагы җимерек өйләргә төште. Болар барысы да: «Бу синең эшең, бу синең хезмәтең!»— дип шелтәләгән кебек булганга, ул бу уйдан котылыр өчен өенә борылды. Ишек бусагасына килеп басканда, еракта гына бердәнбер — ике мылтык атылды, аннан соң тагы жавап бирелүе колагына бәрелде. Гаскәрлек тормышында мондыйларны бик күп күргән булса да, бу тавышлар бүген аркасында суык йөгертте. Шуннан котылыр, качар өчен кебек тиз генә ишекне япты. Селкенеп-селкенеп яна торган кечкенә шәмне янына алып тагы ятты. Кулы ихтыярсыз өстәлдәге кызының хатына барып тиде. Ул инде ул хатны бүген өч мәртәбә укыды, әллә нәрсәсен аңламаган кебек булды. Менә тагы бер мәртәбә укырга тотынды. Тагы аңлап бетермәде. Хат кызыннан иде һәм дә Русиядә мәктәптә калган унҗиде-унсигез яшьлек кызыннан, Сөембикәдән иде. Хат та һәр атна килә торган хатлар кебек хат иде.

Ләкин бер йирендәге сүзләре әллә ник полковник Тимергалиевкә ят кебек тоелган иде. Андага фикерләр аның әллә кайларда яшеренеп яткан уйларына барып тигән идеме, бик тирәндәге җәрәхәтенә бәрелеп, аның бетәү ярасын янадан ачкан идеме? Үзе дә аңламаган әллә ни булган иде. Шуннан бирле тынычлыгын югалткан иде. Кызы үзенең шәфкать Һәмширәләр курсына керүен яза вә, болай сугыш булып ятканда, артта тик торуның ярамавын сөйләп, үзенең сугышка китәргә тиешлеге фикерен аңлата вә атасыннан рөхсәт-фатиха сорый иде...

Ул бер калыкты, бер уянды. Авыр бер йокыга китте. Саташа башлады... Менә аның күз алдына үзенең зәгыйфь кенә кызы килеп баса. Аның янында аның күптән тугел генә сугыш мәйданында каһарманча үлгән бердәнбер угылы килеп урынлаша. Алар артында күптән инде вафат иткән аның хатыны моңлы гына күзе берлә ялынган кебек, ялварган кебек кулын суза: аның бер кулы кырт итеп киселгән, манара киселгән кебек киселгән... Аның догага күтәргән ике кулы йирендә бер кул, бер җиң генә селкенә. Бер кулы юк. Нәфисәнең бер кулы киселгән! Полковник куркына: «Нәфисәме син? Әйе, Нәфисә!..
Шулай, Нәфисә, шулай!.. Синең шул бер кулың киселгәндер... Сугышта киселдеме?.. Кем кисте, дошманмы? Безнекеләрме? Дошман кем?» Аның күзе алдында әллә никадәр киселгән куллар, аяклар, мәсхәрә ителгән төрек хатыннары, кызлары үтә... «Сиңа да, Нәфисә, шулай булдымы?.. Әллә сугыш сафында каһарманча үлгән угылың өчен шулай җәрәхәтләндеңме?»... Ул сискәнеп уянды. Тагы күзен ачты. Тагы шарт-шорт йөреп фикерен әрчемәкче булды, ләкин кара уй аны ташламады..

Ул бераз эш берлә мәшгуль булмакчы булды. Шуның берлә кара фикерләрне кумакчы булды. Кызына кайчан соң жавап язар? Ни язар?.. «Иртәгә, иртәгә!» Ул штабтан килгән бер кәгазьне ачты, аны укырга тотынды. Укыды, укыды. Берни аңламады. Ләкин укыган саен йөрәгенә әллә нәрсә кадалган кебек булды. Язучының: «Анатули төрке берлә Иран төркен аерыр өчен алган йипләргә казаклар утыртырга кирәк, шул казакларны Форат, Дэҗлә буена кадәр сузарга кирәк; Дон казагы, Урал казагының элекке гасырларда төрек милләтләрен аеруда иткән хезмәтләреннән файдаланып, бунда Форат казаклыгы мәйданга китерергә кирәк», дигән фикере бунын башында әйләнә башлады. Ул уй аның балалар тегермәне кебек шалтырады. Полковникның күз алдында бернәрсәне ачып җибәрә алмады, фәкать күңелен сыкратты, эчен әллә ник яндырды.

«Бу ни дигән сүз соң? Бу ник соң?.. Бу ике төрек илләрен аеру ник кирәк соң?» Ул жавап таба алмады... Кызына хат язарга тотынды. «Бу сугышта бер угылым һәлак булды, инде бер кызым —син калдың. Синең дә һәлак булуыңны күрәсем килми»,— димәкче булды. Ләкин хат язарга дип башлагач та, күзенә кәгазьнең почмагынадгы штаб мөһере ташланды. Үзен «полковник Тимергалиев» игеп хис итте. Каләме икенче якка китте. Хатында сугышга үлүләрне мактады, каһарманлыклардан бәхәс итте. Кызына килеп җитте, каләме тотылды, бер сүз таба алмады. Бер укып карады, ике укып карады, тагы каләм йөремәде. Ник соң ул әле кызына русча яза? Ул бит бик һәйбәт төрекчә яза белә, кызын да махсус мөгаллим алып укытты, ник соң ата берлә бала арасындагы мөнәсәбәтне рус сүзләре

берлә йөретә?.. Ул яңа фикер ачты кебек булды, сөенде, шатланды. Кызына татарчалатып язарга тотынды. Сәламнәр бетеп, сугышның каһарманлыкларына килгәч тә, каләм терәлде. Аның татарча иттереп, үзенең кызына шул сугышны бик шәп иттереп язарга теле бармады. Татар гәзитәләрендәге сугыш хакындагы карашмы ирек бирмәде, татарча язган хаты русчасына тәмам башка булып чыгачак булды... Ул тагы туктады. Ике хатны да алып ташлады... Башында авыру сизенде, тәнендә ватылу хис итте. Гаскәрчә иттереп чишенер-чишенмәс кенә тагы урынына сузылды. Аның күз алдыннан бик озакка кадәр кызының сыны, аның хатынының бер киселгән кулы берлә күккә таба карап дога кылуы югалмады. Ул әйләнде, әйләнде, таң алдында гына акрын гына йокыга талды.

* * *

Полковник Тимергалиев инде Кавказ җәбһәсендә бер елдан артык. Ул Сарыкамыш сугышына ярдәмгә җибәрелде. Анда килеп өлгерә алмаса да, Әрзерумга таба барышта уң канатны саклады. Трабзонны алганда да аның атлылары төрекләрнең аңсыз һөҗүмнәренә каршы торды. Аннан ул җәнүбкә табарак ташланылды, рус гаскәрләре берлә Багдад астында сугышта торган инглиз гаскәре берлә кушылу хәрәкәтеңдә аның алаена зур йөк йөкләнелачәк булды. Ул буйда егетчә бер хәрәкәт ясар өчен төрекләрнең иң сыек нокталары хисап ителгән йиргә урынлаштырылды. Шуның өчен Русиянең төрле халыкларыннан тупланган аның алае айлар буе хәзерләнде, көчләнде вә шул уйның артыннан полковник Тимергалиев тә бик күп куды вә бик күп хезмәт сарыф итте. Шул тарихи эшне эшләүдә дөнья сугышында, инглиз сугыш сафы берлә рус сугыш сафының берләшүенә сәбәп булса, ул бит бик зур хезмәт иткән булачак, аның бит тарихка исеме керәчәк. Аның бит исеме-аты бөтен хәрби мәктәпләрендә авыздан-авызга йөриячәк. Ул бит каһарман булачак... Дәрәҗә дә үсәчәк, узе генераллык (пашалык) дәрәҗәсенә менәчәк: Генерал Тимергали булачак!..

Менә шул фикернең артыннан бер адым калмады. Шуның өчен ул бөтен гаскәрләрен аерым-аерым кебек хәзерләде, бөтен атларны аерым-аерым кебек күздән кичерде, бөтен коралны үзе тикшерде, бөтен мәгълүматны үзенә җыйнады, һәрбер төшкән төрек әсирен үзе сорады, аның янынннан тапкан һәрбер кәгазьне үзе җентекләде. Тау араларында карлар азаеп, атлыга йөрергә юл ачылачак вакытка кадәр үзенең бөтен алаены тәмам иртәгә юлга чыгарлык иттереп хәзерләде. Шулар тәмам булып, баш команданлыктан «Алга!» дигән әмерне көтеп торганда, беркөнне полковник Тимергалиев штабка чакырылды. Үзенең ни өчен чакырылганын белгәнгә, үзенең планын, үзенең планы хакындагы бөтен дәлилләрне алып чапты. Барып җиту берлә үзенең команданына сәламгә китте. Аны яшь кенә, йомшак кына бер рус бояры бай бер өйдә кабул итте. Иртә чәй вакыты булганга, полковникны чәйгә утыртты. Рәсми мөгамәләләр бик тиз бетеп китеп, генерал өй хәленә кереп китте. Өйнең тарлыгыннан зарланды, хатынының бундый йирдә торырга өйрәнә алмавыннан, килгән грузиннар берлә, азәрбайжанлылар берлә көн дә очрашкан скандалларын сөйләде. Аннан сәясәткә күчте. «Петербургта ни бар соң? Ни төшенәләр?»— дигәнгә каршы: «Ни барын белмисезмени? Распутин бар! Распутин! Без хәзер һәммәбез Распутин фикеренең хезмәтчеләре... Ул, каналья царица берлә бергә, ничек булса да безнең гаскәрне бер уңайсызлыкка төшереп, солых ясатырга маташа»,— диде. Аннан булмады, генерал мәгашнең җитмәвенә күчте. «Тормыш бәһаланде. Мондагы төрле-төрле татар, әрмән, гөрҗи сәүдәгәре һәркөнне бәһане кутәрә, читтә яһүдләр безнең акчаның курсыны төшерә. Иранда хәзер безнең кәгазь акчага фәндык та алып булмый, алтын, көмеш сорыйлар... Дума бертуктамый бутый, белепме, түгелме — кем белсен? Тыл жимерелә. Менә Николай Николаевичны монда җибәрделәр. Себергә җибәрделәр, ул хурланган... Бөтен үчен мондагы халыктан, бездән ала!.. Сөйләмә! Полковник, сезнең хәл тыныч, сез үз эшеңездә, без монда кырмыска оясында»,— диде.

Полковник Тимергалиев бу тәмсез сүзләрдән өшеп, үзенең алаеның хәлләрен сөйләде. Житеп бетмәгән пулеметларны тизрәк жибәрүне һәм лә патронның озын сәфәргә житәрлек булмавын, шулар тулгач, беренче әмердән соң алга барырга хәзерлеген аңлатты...

Генерал аптыраган кебек карады: «Сез һаман алга! Армыйсыз да! Без монда ничек фронтны саклый аламыз дип йөримез. Төрекләр гаскәр ташыйлар. Алмания туктамаенча яңа корал күндерә. Сул канатта мажар эфисәрлөре күренде. Төрекләрнең Кавказга таба хәрәкәт итүләре көтелә. Бундагы халык бит, беләсең! Бүрене никадәр ашатсаң да урманга карый. Азәрбайжанлылар арасында төрек эфисәрләре әшли. Грузиннары да ышанычсыз. Әрмәннәр генә менә безнең яклы». Алары да бит шул карапет гаскәрне талыйлар, суялар... Тагы анда — тылда: Мәскәүдә, Казанда, Бакчасарайда, Бакуда бик куәтле төрек агитациясе бара. Баш команданның әмере берлә бөтен татар эфисәрләрен, гаскәриләрен гарәп җәбһәсенә жибәрдек... Батенька мой, болар бары да эш!.. Кирәкмәгән эш!..» Генерал электрик шылтыравыгыны басты. Ишектән күренгән кызыл битле, таза хезмәтче кызга: «Маша, минем кабинеттан зур портфельне китер әле!—диде.—Менә полковник, бернәрсә күрсәтим әле, сезнең фикерне сорыйм!»

Хезмәтче кыз китергән портфельдән чыгарып, Мәскәүдә чыккан бер татар гәзитәсен сузды.

%s Менә гәзитә, күрәмсез, гаскәри бер цензур астында чыга. Менә караңыз әле әнә шул мәкаләне! Монда, шәһәрдә калган татар гаскәриләре бәйрәмнәрендә казармага алып килгәннәр. Сугышка каршы булырга кирәк. Әллә ничә йирдән җыелып-җыелып укыган гаскәриләрдән алдылар. Шуны, зинһар, укып, фикереңезне сөйләп, мөмкин булса, тәрҗемә иттереп жибәреңез әле: сездә бит анда тел белә торган эфисәрләр бар...

Тимергали кызыл берлә сызылган мәкаләләрнең башына күз атты. Аның күзенә башындагы «Бәйрәм корбансыз булмый, корбан бәйрәмсез булмый» дигән сүз ташланды. Ул:

%s «Эшләтермен, генерал!— дип портфеленә тыкты... Күрешеп чыгып штабка китте.

Штабның кабул бүлмәсендә ул әллә никадәр әрмән, яһүди, гөрҗи сәүдәгәре тапты. Алар янына чыккан бер эфисәрдән берсе шикәр китерер өчен вагон сорады, берсе дөге җибәрер өчен кәгазь эстәде, берсе атлар сатып алып китерер өчен аванс акча, берсе төне-көне ябылмый торган ресторан ачарга рөхсәт сорады. Яшь эфисәр бик күбесе берлә кул биреп күрешеп, акрын гына сөйләшеп, төрле-төрле күз карашлары берлә ишарәләр ясады. Әллә нәрсә хакында әмер итте. Тимергали янына кичеп:

%s Хәзер, хәзер, мин сезнең хакта сөйләдем, генерал бераз мәшгуль, хәзер!— диде. Тагы әллә нинди яһүд берлә акрын гына сөйләште. Аның кулындагы кәгазьне алып кереп китте. Тагы чыкты. Сораучыларга кзгазьләр, әмерләр, фәрманнар таратты. Полковникны тагы күреп, бу моңча ни эшләп тора дигән кебек булып: «Хәзер, полковник!»— дип кереп югалды.

Тиморгалинен эче поша башлады, ачуы килде. Ул адъютантка бик каты иттереп сейләргә хәзерләнеп җитә алмады, генералның ишеге ачылды, аннан бик каты кычкыру чыкты: «Вон, вон, вон!» дип кычкыру, сүгенү ишетелде. Ишектен туп кебек тәгәрәп, кып-кызыл кызарган, башында чалмалы, муенында медальле бср кеше килеп чыкты. Ул шулкадар аптыраган иде, кая барырга белмәенчә йөдәп калды. Әллә кайдап чыгып, аның янын бер-ике мөселман сырып алды. Аның бер суз дәшмәенчә торуына карамаенча, алар кызу-кызу сорашырга, аллә нинди сөальләр бирерга кереште. Лакин теге медальле кеше бу сузларгә җавап бирмәде. Акрын гына:

— Дин, миллэт дошманыңнан ни көтәсең!— дигән сузне Тимергали ишетте... Тегеләр чыгып китеп, бераз бушагач, бер әрмән күршесенә:

— Бу мондагы мөселман мөфтисе, алар монда төрек яклылар, генералдан эләкте үзенә!— диде дә, черегән тешләрен күрсэтеп көлде. Читтәрәк торгам зур гына корсаклы бер урыс сәүдәгәренен:

— Барысыны бетереpте кирәк иде, безнекелар йомшак. Монда алар Гайса галайһиәссәлам куенында торган кебек яшилар дә, шуның да кадерен белмиләр, Төркиясена китсеннәр!— диде...

...Полковникнын әллә кай җирен бу манзарә мыскыл итте. Аның әллә нәрсәсе тагы

хурланды. Ул шул хисларен урынына китереп житкерə апмады, адъютант:

— Рахим итегез!— диде. Тимергали кереп гаскәрчә сәлам бирде. Зур мыеклы казачий генералы карты килеп кул биреп курешеп:

— Рахим итеңез, рəхим итенез!— диде. Тимергали бу генералны: «Мин кайда очраткан идем сон?»— дип, башында əзлəргə тотынды. «Исəнлекме, полковник!— Фəлəнме?— Сез картайгансыз!» Полковник Тимергалиев:

— Сон сез мине күрганеңез бар идеме, генерал?— дигəн сөаленə:

— Ник булмасын, без бит япон сугышында сезнен берлə берга булдык. Порт-Артурда сез 12 нче номер фортларнын команданы идеңез, мин 15 нченеке идем. Мин ул вакыт штабскапитан идем!— диде...

Тимергали хəтерлəде... Әйе, Тимергали ул вакыпта ук капитан иде, хəзер дə əле һаман полковник кына. Бу урыс менə ул вакытта малай гына иде, хəзер моның башлыгы булган. Аның күзе алдыннан ботен Порт - Артур сугышының манзарəлəре кичте. Бу, хəзерге генералның, урынын ташлап качып, Тимергалинен артын ачык калдыруын, Тимергалинен бик зур каһарманлык берлə, əллə никадəр гаскерен югалтып, узе җəрəхəтлəнеп кенə вазгыятьне саклый алуын, моның өчен узенчə рəхмəт алуын, бу казачийнын Георгий медале алуын хетерлəде. Куңеленнəн бер күнелсез агу акты.

Рəсми мөзакəрəлəр озакка бармады. Тимергали иртəгə сəгать 11 дə штабның кинəш мəжлесенə чакырылганын белде вə китмəкче булды. Лəкин генерал һаман полковникны тотмакчы, аның берлə ачылып китмəкче булды. Япон сугышы начар тəэсир иткəнен аңлады булырга кирэк, донья хəленə керде. Гаскəргə əйбер куючылардан зарланды. Бакуга барып, андагы башбаштаклыкны бетерергə карарын сөйлəде. «Анда, Бакуда, гаскəрнең тылында Төрек пропагандасы бара. Андагы татарлар төрек əсирлəренə ярəом итəлəр, арттан сугышка хəзерлəнəлəр икəн: əле менə мөфтилəре килгəн иде.

— Безнең, ди. җəмгыяте хəйриямез сугыш астында ятим калган балаларны карар ечен бер ятимхане ачарга булды. Жимерек төрек авылларыннан шул балаларны җыеп килергə рөхсəт биреңез, ди. Качакларга ярдəм комитəсе ясадык, ди.

— Польшадан, Курляндиядəн, Лифляндиядəн качкан никадəр чын урыслар бар, шуларга ярдəм итеңез,— дидем.

— Безнен халык шул буны тели,— ди. Аина, фронтка барып, безнең мəми авызлардан мəгълумат жыеп, төреклəргə җасуслык ясамакчы булалар. Ачуым килеп, куып чыгардым. Шундый нахаллар. Кавказ урынбасары йомшаклык берлə базындырып бетергəн. Монда миңа өч елга гаскəри куəтне бирсəлəр, мин курсəтер идем... Грузиныннан, татарыннан, дагыстаныннан көллəр очырыр идем. Безнен хөкумəт йомшак. Думасы, гəзитлəре бары да безге дошман, бары да мəмли! Ишеттеңме əле, менə хəзер бер француз, бер инглиз полковнигы килделəр. Мондагы хəл берлə танышалар, ди. Мин курсəтер идем аларга фронтны. Барысы да масон, барысы да жасус, бездə жөмһурият ясарга йөрилəр. Ишетгеңезме? Алманнар безнец берлə солых ясарга телилəр: Истанбул сезгə, Франсə шимале безгə, дилəр. Лəһстаннан чыгалар. Иске чиклəрне безнекелəр Карьятка барып терəтмəкчелəр. Юкса кан түгүдə ни файда, килешерга кирəк иде, эчне сакларга кирəк, эчне, полковник!

Тимергалинец эчкə кереп китмəгəнен күргəч, генерал:

— Курешермез əле, полковник, əчеңез пошса, бүген кичкə без — «Кара мече» ресторанынад. Анда беркем дə булмый, ул безнең штабныкы кебек, килеңез!— диде.

Тимергали əллə нинди чуалчык уйлар, фикерлəр берла урамга чыкты. Аш вакыты җиткангə, акрынлап кына гаскари клубкамы барып, йə бер ашханагəме кереп аш ашарга уйлады. Акрынлап кына шаһарнең матур урамнарыннан зиннəтле киенгəн-ясанган хатын-кызлар арасыннан үтеп, вак-төяк нəрсə алыр өчен бер кибеткə керде. Кəгазь алды. Шоколад, конфет алды, кызына булəк иттереп җибарергə дип җефак яулык, чигелган бер матур янчык алды, касса янына түлəргə барды. Буның алдындагы бер хатын кузен тутырып карады кебек булды. Полковникка да бу хатын таныш кебек куренеп китте. Ул да башыннан əзлəргə кереште. Менə акча тули башлады. Касса хатыны берла бер-ике сүз сөйлəде. Акчасын

тыгып өлгерә алмады:

— Сез полковник Тимергалиев тугелме?— дигән татарча бер тавыш ишетте. Полковник борылды:

— Әйе!

—Исәнмесез! Без сезнең берлә таныш идек, инде бик куп вакыт утте. Сез онытkансыз, мин Нәфисәнең дусты Әсма. Мин монда бер азәрбайҗанлыда кияүдә, мин сезнен туйда да булдым.

Полковникнын күзе алдына бердән Нәфиса, аның туе, туйдагы кызлар, егетләр килеп басты. Бу картаеп килә торган хатында чын да шундагы бер туташны таныды.

— Гаеп итмаңез, картаелды, онытылган, фәлан,— диде. Хатын бик озак итеп сөйләп китте. Нәфисәнең үлүе вакытларына кадар сорашты. Угылы, кызы хакында мәгълүмат алды. Ахырдан Тимергалинең вакытлы гына монда икәнен белеп:

— Аш ашамаган булсаңыз, әйдәңез безгә кайтыйк, минем ирем сезне күптән ишетеп белә. Ул адвокат. Бик шат булыр иде,— диде. Тимергали үзенен киеменнән, кыяфәтеннән тартынды, ләкин Әсма аны көчләгән кебек атына утыртып алып китте.

* * *

Адвокат Үлмәс угылы өенда полковник Тимергалиевне бик ачык кабул иттеләр. Картаеп килә торган адвокат Арыслан, аның хакында хатыныннан бик күп ишеткәнгә, иске танышы кебек бердән ачылды. Балалар хәленнән сорашты. Үзенең өй хәлләрен, балаларын сөйләде. Озакламады, аш та бирелде. Пөхтә иттереп эшләнгән аш бүлмәсендә Тимергалигә егерме ике, егерме өч яшлек Фәридә, унҗиде-унсигез яшьлек Зайнәп исемле кызлары да күрештерелде. Ашка утырып беткәч кенә әллә кайдан бик ашыгып кайткан кебек килгән студент угыллары — Ибраһим да таныштырылды. Аш башланды. Казан ысулында пешерелген пилмән күптән бирле гаскәр ашына өйрәнгән полковникка үткан гомерен хәтерләтте, аның артыннан килгән пылау, аның артыннан бирелгән шурпалы Казан бәлеше аның тәмамән гаскәрлеген, полковниклыгын оныттырды. Үзенең гаилә тормышы, Оренбургта вакытта хатыны, әбисе берла берга торуларны хетеренә китерде.

Ул сизмәенчә дә шул гаиланең әгъзасы кебек булып китте. Әсма ханымның бертуктамаенча сыйлавына, яшь кыз Зайнәпнең бертуктамаенча әллә нинди кечкенә нәрсәләр сөйләвена, Ибраһимның тик кенә, ашына таба карап, моңарга дошманчарак күз ыргытуларына тәмам өйрәнде, үзләнде. Аш артыннан аш килеп, сүз артыннан сүз китте. Ләкин һәммәсе Тимергалине узенен хатыны, баласы-чагасы, гаилесе, тормышына таба өстерәде. Аларның хатирәләрен яңартканнан-яңартты. Фаридә полковникның кызы Сөембикәне бик сорашты. Аның кайда укуын, ни булырга, нинди юлны алырга телеве хакында белеште. Үзенең Петербургта әдәбият-тарих факультетында укуын, андагы иптәшлере тормышын, үзләренең әдәби түгәрәкләре хәятын аңлатты. Зәйнәп, апасын бүлеп-бүлеп, үзенең музыка мәктебендә әрмән кызлары берла оршышканын, бер марҗа берлә Таниев татармы-тугелмелеге хакында ядәч аерып, аны отканын анлатты. Арыслан әфәнде, балаларының полковникка яхшы тәэсир калдырганын күреп, эченнән рәхәтләнеп утырды. Угылы Ибраһимны сүзгә катыштырыр өчен берничә мәртәбә аңарга сөальләр бирде. Ләкин студент һаман ачылмады, ул мәче барны хис иткән тычкан кебек үзенең оясыннан фикерлерен чыгармады. Аш тәмам булды.

Төрек каһвәсе кунак бүлмәсендә бирелде. Каһвәләрен эчәр-эчмәс, Фәридә пианинога утырды. Зәйнәп йырларга хәзерләнде. Әсма берлә Арыслан кунакның берсе бер ягында, берсе бер ягында сүз берлә мавыкты. Ибраһим почмакта гына естәлгә сибелген гәзитә-мәҗмугаларны актарып маташты. Менә бердән музыка башланды. Тимергали әйтә торган сүзен онытып, музыка тыңларга тотынды. Нәфисәнең сөеп уйный торган «Ашказар»ын Фәридә моң иттереп уйнап җибәрде. Аның юл алуын көтеп торган Зәйнәп тамак тавышы берлә, җыр берлә кушылды. Аның хәтфә кебек йомшак тавышының каймак кебек ягымлы агышы Тимергалине тәмам исертте. Ул узенең яшь вакыттагы хатыны берлә Дим буенда

кунакта йорүләрене, шундагы матур, ямьле чакларны яңыдан хәтерләде, шундагы дөньяда гизде. Зәйнәпнең эшләнгән тавышы ачылганнан-ачылды. Ул полковникның ишетмәгән борылу-сузылуларын бирелеп йырлавында дәвам итте. Фәридәнең кулында пианино еглаганнан-еглады. Ул иске «Ашказар»нык кайгы-хәсрәтенә бу көнге аһны, бу көнге моңны, бу көнге юксыллыкны, бу көнге мыскыллауны кушты...

«Ашказар»ны «Сакмар суы» алыштырды. Аның артыннан «Галиябану» килде, аның артыннан «Тәфкиләү»е, аның артында полковник ишетмәгән «Ләйлә-Мәҗнүн», «Аршын-мал-алан» операларынынң парчалары, азәрбайҗан, комык йырлары уйналды, йырланды. Зәйнәп ачылганнан-ачылып һаман йырлады, Фәридә һичбер арымады, һаман уйнады. Полковник Тимергалиев һаман тыңлады, туймады, тыңлады. Кызлар туктагач та, тагы берәрне уйнаңыз, дип сорап, тагы уйнатты. Мене Әсмабикә, «Тимер маршы», диде. Ике кыз пианинога угырып, дүрт кул берлә, «Аксак Тимер маршы»н уйнадылар. Бу марш үзенең куәте, көче берлә Тимергалинең астын-өскә китерде. Ул аны тагы полковник итте, тагы атлы гаскәрнең башлыгы итте, Аксак Тимернең гаскәри маневрларын күз алдына бастырды. Ләкин үзенә, гаскәрләренә әллә нинди башка киемнерне, Тимернең гаскәр тарихын генераль штабта укыганда күргән Тимер гаскәренең чыгтай киемнәрен кидерде. Аларнын, кыяфетлерен бирде. Ул шул кыска музыка уйналганда Тимернең бөтен тарихын Тимер берлә бергә үткән кебек булды. Тимернең шул зур хәрәкәтендәге гаясен, фикерен эзләде. Аны хәзерге ишеткән Идел буе музыкасының еглавы, ыңрашуы, сыкрануы астында әзләде. Каһарман Тимер Идел буена барып Алтын Урданы җимермәгән булса, бәлки бу монлы «Ашказар» көе, еглый, сыкрый торган «Тәфкилеф» көе тумаган булыр иде. Бәлки Идел буенын угылы, полковник Тимергалиев төрле торек кабиләсеннән җыелган атлы гаскәр берлә, ике башлы кара кош байрагы астында икенче төрекләргә каршы сугышмаган булыр иде. Бәлки ике башлы кара кошның канатлары да бу кадәр озынга, Кавказ тауларына кадар, Тимернең үзенең кабере яткан алтын Самаркантка — Төркстанга кадар сузылмаган булыр иде. Бәлки ул хәзерге кебек Даҗлә, Форат буйларына таба тешләрен ыржайтмаган булыр иде. Истанбулга, бугазларга кадәр ерткыч теше арасында кутәргән тәресен китерергә көчләнмагән булыр иде...

Бу музыка Тимергали берлә бу гаилә арасындагы бөтен пардәләрне ачып, арадагы бетен ятлыкларны бетерде. Музыка беткач, хәтта Ибраһим да бер кочак гәзиталәр, мәжмугалар китереп Тимергалинен алдына салды. Тимергали «Мулла Насретдин»ны күздән кичерде, аның рәсемнәреннән туйганча көлде. Төрле Баку, Казан, Оренбург, Мәскәу, Уфа гәзитәләрен берәм-берәм карап үтте. Күзена теге баягы штабта бирелгән гәзитә ташланды, шуны алды, әйләндера башлады. Арыслан шуны куреп:

— Мена, полковник, гажәп мәкалә, теләсәңез укыйм әле!— дип күзлегене эзли башлады. Бер кесәсен актарды, икенчесен актарды, таба алмады. Угылына карап:

— Угылым, күзлегем юк икән, укы әле!— Полковникка:

— Картаямыз, күзлексез укый алмыйм инде,— диде. Полковник та баш иеп жавап бирде. Ибраһим, шигырь әйтерга хәзерләнгән артист кебек, ачык тавыш берлә, туктар йирләренда туктап, киракле йирларенә мәдләр куеп, укырга тотынды.

Мәкаләнең фикере бик тиз полковникны биләп алды. Ул узен-узе сизмәенчә мәкаләнең эченә кереп китте. Аның фикерләренең бормаларында йөреп, аның йөрәккә кадый торган урыннарында йөрак әрнүен хис итте. Аның мантыйкы артыннан барып, аның нәтиҗәсен алдан сизенде. Мәкалә бетте.

Еракта гына тыңлый торган Зәйнәп:

— Дөрес бит, без бит һәммәмез урыс өмәсенә корбан булучылар... Бөтен халкымыз, бөтен зыялымыз, бөтен гаскәремез урыс өмәсенә йөри,— диде. Шуңа полковник эченнән генә: «Әйе, шуңарга карш өмә өйрәсе бирелә, артыгы юк»,— димәкче булды. Япон сугышындагы бөтен рус иптәшләре икешәр, өчәр дәрәҗә кутәрелдекләре вакыт, үзенең мең база берлә бер дәрәҗә күтәрелүе күз алдына килде. Ззйнәпне Ибраһим булде:

— Урыс өмәсе дигән сүз дөрес түгел. Урысның пролетариаты үзе дә өмәгә йөри. Урысның буржуа өмәсенә дияргә кирәк иде,— диде.

Фариде:

— Сөйлисең юкны! Һәммәсе — бер урыс, кая аның пролетариаты! Ул ни эшләгән ди, безгә килгәндә, бар да кара урыс!

Ибраһим:

— Юк, урыс берлә урыс арасында аерма бар! Капитализм өчен яңа базар кирәк, ул шуңарга Иранга ташлана, Төркиягә каршы сугыш ача. Бу сугыш та буржуа мәнфәгате өчен әшләнә, пролетариат моңар — хилаф!— диде.

Арыслан бераз чыраены сытты. Әсмабикә полковникка карап:

—Менә һич тыныша алмыйлар, берсе милләтче, берсе социал-демократ!

Полковник Ибраһимга дустча күз берлз карады:

— Яшьлек, Әсмабикә, яшьлек, вакыт килер, һәммәсе дә үтәр! - диде.

Фәридә:

— Юк, безнең Петербургта студентлар, курсисткалар тугәрәгендә — барысы милләтче. Хәзер безнең изелгән халыкнык баласына башка юл юк та. Урысның йерәгемезгә кадәр итеге берле басканын һәркөнне курә торып, милләтче булмаска, белмим, кем булырга кирәк?! Уз халкың дошманы берлә бергә ничек булырга кирәк?!

Ибраһим:

— Изелү, кысылу масьәләләрен милләтчелек хәл итә алмый, аны фәкать социализм гына ачып бетерә. Социализмда милләт, дин аермасы юк. Аңарда пролетариат бар. Һем до буржуа бар. Болар һаман бер-берсе берлә сугышып торалар,— диде.

Полковник сузне буләр өчен:

— Кайда укыйсыз?— дип сорады.

Ибраһим:

— Одесса дарелфөнүнендә,— дияргә өлгермәду, Зәйнәп:

— Одесса яһудиләреннән шундый яһуд фикерлерен өйрәнеп кайткан!— диде. Узенең сузе бик матур тоелдымы, көмеш кебек тавышы берлә шылтыратып көлде. Әсмабико сүз буләр өченме:

— Чәйгә рәхим итегсз! — дип аякка торды.

Аш булмәсенә кереп, озын иттереп, иске чакларны сөйләп чәй эчтеләр. Чәй бетәр алдыннан Зәйнәп:

—Бүген безнең «Жәмгыяте хәйрия» сугышта ятим калган балалар файдасына кичә бирә, без да уйныймыз. Сез, полковник, барамсыз?— диде.

Тимергали:

— Бик теләп барам. Ләкин кай вакыт, кайда?— диде.

Зәйнәп:

— Грузин клубында бүген кич сәгать сигездә,— диде. Полковник, кич буш икәнен белеп, барырга вәгьдә бирде. Китәрге дип урыныннан калыкты. Арыслан да, Әсмабико дә икенче Тифлискә килгәндә узләренә тугры төшәргә үтенделәр.

Бик күп фикерләр, хисләргә чумып, яндрган кебек булып Тимергали булмәсенә кайтып китте. Шул фикерләрне сеңдерер, шул хисәрне әшләтеп бетерер өчен кебек уйлана-уйлана озын кәнәфигә сузылды. Бик озакка кадәр бу яңа гаилә берлә өй жәмәгате күз алдыннан китмәде. Бик озакка кадәр алар бер-берсенә катышып, карашып, яңа төсләр алды. Бик күп яңа фикер, яңа уйлар тудырды. Шуларның әле берсе артыннан, әле берсе артыннан куа-куа башы арыды, күзе йомылды, йоклап китте.

* * *

Шылтыр-шылтыр су агуы кебек бер моңлы тавыш аның йокы арасына керде. Фәридә акрынлап кына бер моң көйне уйный кебек булып китте. Яшел үләннәр арасында, еракта гына сарык көтүе килә кебек булды. Дөбердәп үткән тимер юлы еракланган саен тавышын азайтып, ерагайганнан-ерагая кебек хис ителде... Ул тагы йоклап китте, тагы колагына әллә нинди тавышлар кереп чыкты. Менә кайдадьр сәгать сукты. Тимергали кузен ачты.

Караңгы, тын бүлмәдә үзен ялгыз күреп, кайдалыгын эзләргә кереште. Өй ягы пыяла ишектән кергән ут яктысы аның бүлмәсендә уйнады. Ул почмакта эленеп куелган узенең гаскәри киемен күрде. Кайдалыгы хәтеренә төште. Шуны ныгытырга өлгермәде, колагы тубендә бытыр-бытыр кемдер ваклап сөйләргә тотынды. Бүлмәдә кем бар икән дип башын күтәрде. Караңгыда беркемне күрә алмады. Күзе бер шәуләгә дә очрамады. Колагы очыннан килгән шул тавышны тотар өчен кебек кулы бердә капшанды. Кулы күрше будмәгә чыга торган ишеккә тиде. Шуннан тавыш килгәнне сизенеп, тагы күзен йомды. Русча сөйләнә торган сүзләр, бигрәк то андагы бер тавышның бик таныш кебек булуы аның дикъкатен җәлеп итте. Ул таныш тавышның хуҗасын әзләргә кереште, аны таба алмаса да, сүзләрне тәмам анларга тотынды.

Күрше бүлмәдә ике кеше газ керү солы кую хакында сатулашалар.

— Потын фәләннән уткәрермез. Фәләннән булыр комиссионы ике йөз мең тәнкә булыр,— дигән жөмләне эләктерде. Аның артыннан икенчесе сөйләргә кереште. Солының бәһаләрен, озын юлларын, фәләннәрен, ике йөз меңнең күплеген, эшнең күтәрә алмавын сөйләп, «Николай Иванович, узеңез беләсез, фәлән», диде. Тагы акрын гына бытырдау китте. Икенче тавыш ике йөз меңне буләргә тотынды:

— Интендант башлыгына илле мең, кул урду башлыгына илле мең, канцелярия башлыгына 30 мең, Василий Егоровичка 25 мең, мина да бит кирәк, өч йөз илле тәнкә мәгаш берлә күпкә бара алмыйсың, фәлән,— диде. Тагы сатулашу китте, тагы ике яктан да торле дәлилләр китереше. Иөз илле мең мәсьәлә хәл ителде. Гаскәргә башка кирәк-яракны кую хакында суз китте. Полковник бунда, бунын гәскәренең, атларының солысы таланганын, буның гаскәриләренең ашамагы-әчмәге урланганын аңлап, кемнәр әшләгәнне белмәкче булды. Шул ишекне ачып, шуларны элактереп, урду башына барып сөйләргә, Кавказ урынбасарына язарга уйлады. Сикереп торып, булмогә кереп тегеләрне тәвәккыф итмәкче булды. Тагы күз алдына солых вакытында үзенең интендантлар берлә булган бер низагсы во шунда, буның тарафында хаклык була торып, буның шелтә алуы, тегеләрнең урлауларында дәвам итүләре күз алдына килде. Шул фикердә карарга килеп житә алмады, бик каты шылтыраган чыңгыравык тавышы буны куркытып җибәрде. Күрше бүлмәдә ишек ачылды. Хуҗа эчемлекләр китерергә кушты. Тимергали урыныннан торды. Уталды, сәгатенә карады. Җиде тулып үткәнгә, торып әдәбият кичәсенә хәзерленерге тотынды, киенеп бетеп чыкты. Әллә никадәр шешәләр тутырган поднос күтәргән хезмәтче каршысына килде. Әллә кайщан килеп чыккан кечкенә генә малай күрше бүлмәнең ишеген ачып җибәрде.

Тимергали бүлмәдә бүгенге птб начальнигының канцелярия башы берлә өстәл янына утырган бер әрмәнне күрде. Никтер аның күзе: «Чын да шулмы икән? »— дип канцелярия башына текәлде. Канцелярия башы да Тимергалине күрде, аның йөзенә кызыл йөгерде... Тимергали:

— Менә ни эшлиләр, менә кемнәр өчен сугышамыз, «урыс өмәсе» дигән дөрес шул! Теге егет — Ибраһимныкы да бөтенләй хата түгел. Шул әрмүн сәүдәгәре, шул бозык аристократ баласының шул тулы поднос шешеләре өчен сугышамыз,— диде. Башындагы ямьсез фикерләрне куар өчен акрын гына кичәгә таба китте.

Әле вакыт иртә булганга, бик алдан барып җитмәс өчен, бер чәйханәгә кереп чәй сорады. Чәй урынына хуҗа үзе килде:

— Сез фронттандыр, арыгансыздыр, монда, билгеле, хәл жыярга килгенсездер, менә бик йәйбә чагырымыз (шераб) бар, шуны әчеңез. Аннан соң монда кабинетларымыз бар, монда рәхим итеңез! Везде ни телисеңез, ул бар... Бик шел кызларымыз бар, пожалуйста, полковник!— диде. Тимергали бар да, юк та дип жавап бирмәсә дә, әрмән сөйләвендә һәм дә үзенең дөханының нигьмәтләрен, зәвекъ-сафаларын мактавында дәвам итте. Полковник хужаның ачуын китермәс өчен:

— Мин әле бер танышка барам, соңрак килермен. Сез соң кайчан ябасыз?— диде.

— Безме? Без бер да япмыйбыз, әнә шул тәрәзәдән чиртсәңез, мин хезметеңезгә

һәрвакыт хәзер,— диде. Тимергали ат алып кичәгә китте.

* * *

Сәгать әле сон булмаса да, зал тәмам тулган, уен башланырга вакыт җиткән иде. Ул урынын алыр-алмас, пәрдә күтәрелде. Бер пәрдәлек көлке башланд. Халык берлә бергә полковник та өеннән — гаиләсеннән разый булмаенча, читтә бәхет эзләгән бер эфисәрнең мәсхәрзлзреннән чынлап көлде. Аның артыннан булмады, ике артист чыгып «Ләйлә вә Мәҗнун» операсыннан бер парча жырладылар. Өченчегә иттереп ике Кырым егете каитарма биеде. Халык кул чабып икешәрләтте. Аның артыннан лезгин биюе биелде. Аның артыннан Казан киемендә бер егет чыгып басты. Сәгыйть Рәминең «Татар йоклый» дигән шигерен куәтле тавыш берлә декламациягә башлады: «Татар йоклый, мин йокламыйм, мин уйланам да уйланам!» Полковник бу шигырьдә узен тасвир иткән кебек тапты. Ахырындагы җавап кына полковникны канәгатлендермәде, аның эчен поштырган масьәләләрне хәл итә алмады. Башкалар берлә ул да кул чапты, яшь егетнең яңадан чыгуын көтте. Сәхнәгә хор чыкты. Фәридә пианинога утырды. Зәйнәп, хорны башлап, «Соңгы азан» дигән җырны җырларга тотынды.

«Сонгы азан! Моңлы азан... Китте Казан һәм Әстерхан»...

Полковникның эченнән бер утлы уй кичте. Ул Казан — Мәскәү сугышларын күз алдына китерде. Шундагы Шәехгалинен ролен хәтерләде. Чырае сытылды, жирәнде... Шул уйны уйлап очына чыга алмады: «Узем сон кем?! Мин сон үзем дә, Кавказда урыс куәтен ныгытыр өчен, Төрек канын төрек баласының каны берлә юа торган кеше түгелме? Мин сон ике торек кабиләсе арасында берлекне кисәр өчен, Форат казаклыгы ясар өчен юл ачарга бушлык хәзерләүче түгелме?» Бу сорауларга күңеленнән җавап таба алмаса да, кәефе китте, күнеле кырылды. Сәхнәдән әйтелгән һарбер съз бунын ачылган җәрәхәтене килеп тия башлады. Ул уңайсызланды, газапланды...

Тәнәфес иглан ителүе берлә аны тагы иске танышлары чорнап алды. Ул буфетка чыкты. Америкaн лотереясына катышты. Кечкенә булмәдәге киоскада каһвә эчте. Бер почмакка хәзерләнгән ашханәдән шашлык ашады. Әллә нинди яңа кешеләр берлә танышты, куреште. Мөгаллим, мөгаллимәләрдән, турәләрдән мөрәккәб Казан халкының өстәленә барып чәй эчте. Арыслан берлә бергә буфеттан шампанский да эчте. Шулардан арып, башы чуалып, китеп читкә утырды. Җанлы яшьләрне җентекләп, аларнын яшлегенә кызыгып, үзенең картаюын кызганып тынырга өлгермәде, аның янына Арыслан таныштырган бер азербайҗан докторы килеп утырды. Доктор:

— Курәсез, полковник, халыкта никадәр җан бар, ләкин без зыялылар шумы оештыра алмыйбыз. Узара әллә никадәр низаг, кычкырыш. Әле Бакуда булдам. Һәр миллионернын үзенә бер жәмгыяте бар. Бөтен зыялы шулар арасына буленгән, бер-берсе берлә тартышып ята. Без бер милли саф ясый алмыйбыз... Беләсез, полковник, узеңез күрдеңез, фронтта никадәр төрек киселде, никадәр бала-чага ятим калды, шуларга ярдәмгә дип эш башладык. Русиянең бөтен почмагыннан кардәшлек кулы сузылды: Идел буендагы гәзитәләр иганә ачтылар, бер Мәскәү төрек гәзитәсеннән генә 135 мен сум акча алдык, Казанда, Оренбургта жыю һаман дәвам итә. Һеркөнге почта кочак-кочак акча ташый. Йөзләп хат ятим калган балаларны асрарга сорый... Өч ай булды, менә кулымызда миллионлап акча бар. Шәфкатҗ чишмәсенең агуы әле һаман туктамаган. Безнең хәбәрләргә караганда, ятим калган бала-чага, тол хатынның саны безнекеләр алган вилаятьләрдә егерме биш, утыз мең, шуларны менә хәзер без, яманмы-начармы, йирләштерә аламыз. Ләкин безгә аларга барып җитәргә имкян юк, штаб рөхсәт бирми. Әрмән күңеллеләре шул ятимнәрне, шул мескеннәрне йөзләп, меңләп суя, хатын-кызны мәсхәрә итә. Төрек кызларын җария иттереп, кәнизәк иттереп шәһәрлердә, авылларда сата... Бунда безнең кулда сатылганнан качкан бер ятим яшь кыз бар. Хикәяләрен ишетсә, адәм түгел таш еглар... Ләкин штабка һичбер аңлатып булмый. Начальникның марҗасы әрмән, бөтен тирә-юньнәре әрмән, кара урыс... Без ни эшләргә теләсәк, төреккә җасуслык ясыйсыз, диләр... Сез үзебезнең мөселман

полковник, сезнең зур урында икәнлегенезне беләмез, шатланамыз. Безгә ярдәм итеңез!.. Шул үлә торган балаларны, рус солдатының казармасы янында хәерчелек итә торган тол хатыннарны жыеп ала белик, милләтнең ярдәмен аларга итә белик. Алар бит гөнаһсыз корбаннар, полковник!..

Саче агарган докторның күзеннән яшь тәгәрәде. Тимергали рәсми генә иттереп бер-ике сүз берлә котылмакчы булды, ләкин күңелендә ачылган җәрәхәт ирек бирмәде. Хөкүмет урынбасарына кермәкче булды. Николай Николаевичка мәсьәләне аңлатмакчы булды. Күз алдына баягы мөфти берлә мөгамәлә килеп басты:

—Соң, доктор, мин ни эшли алам! Кулдан килгәнне эшлоргә хәзермен, ләкин, беләсез, мин дә кеше кулы астында,— диде.

Доктор:

— Рәхмәт, рәхмәт!— дип кулын кысты. —Безгә бернәрсә кирәк түгел, безгә шунда барып халыкны карау, анда ярдәм итү, йортсыз-йирсез калган ятимнәрне бунда китереп гаиләләргә тарату...

Полковник Тимергали:

— Мин иртәгә бу хакта урынбасар кәнсәләриясе берлә курешермен, ләкин ни чыгачагыны белмим. Үземә килгзнде, минем үз тирә-юнемдәге балаларны жыяр өчен, үзем берлә бергә теләсәңез кемне алып китәм, кулдан килгән ярдәмне итәрмен, —диде.

Доктор: «Рәхмәт, рәхмот!»— дип әйтергә өлгермәде, Фәридә бер яшь кенә студентны китереп курештерде:

— Менә бу минем Петербург танышларымнан, сезгә бер йомышы бар, —дип китте.

Студент:

— Мин Петербургтан бунда махсус килдем. Минем агам Батумда сәудәгәр иде. Анда элгәре сәүдә төрекләр берлә дә булганга, билгеле, төрек акчасы да кулында булган. Сугыш башлангач, шуларны җыеп куйган, сәүдәгәр, беләсез, һаман файда итәргә тели. Дошманнары, төрек җасусы, дип күрсәткәннәр. Килеп тентү ясаганнар, бернәрсә дә тапмаганнар, ләкин бер ике-өч мең төрек лирасы тапканнар. Төрек аттын-көмеше дә шактый булган. Хәзер шуны тәүкыйф иттеләр. Берничә айдан бирле төрмәдә ята. Үзе берлә һичбер төрле мөнәсәбәт ясап булмый. Хат та яздырмыйлар. Әтиләр-әниләр бик куркалар. Шул мәсьәләне ачып бирергә миңа ярдәмдә булына алмассызмы икән?— Студент башын иде.

Полковник:

— Сәяси эш юклыпына ышанамсыз?

Студент:

—Тәмам, андыйны аңлый торган кеше до түгел, безгә — яшьләргә дә хилаф иде. Һичбер сәяси нәрсә юк, фәкать — файда иту максаты. Аннан — күршеләренен көнчелеге.— Полковник хатирә дәфтәренә исемен, йирен язды.

Тагы берничә сөальләр бирде, җаваплар алды. Иртәгә белешергә вәгьдә биреп өлгермәде, кыңгырау шалтыраттылар. Хатык тагы залга ашыкты. Бер грузин артисты, рус марҗасы йырлады. Тагы милли парчалар китте. Кичнкң соңлыгын белеп, полковник акрын гына чыгып китмәкче булды, бер кеше берлә күрешмәенчә-нитмәенчә киемнәрен алырга тотынды. Киемне киеп бетерә алмады, карт кына бер хатын килеп кулын тотты. Ярты русча, ярты төрекчә иттереп сөйләргә тотынды. Полковникның, искәртмәстән кулын үпте, егларга тотынды. Тимергали аптырап калды, бернәрса дә аңламады. Хатын ялыну, ялваруында булынды. Чттарак тора торган бер егет килеп мәсьәләне аңлатты.

Болар чиркәсләр икән, бер угылы туземный гаскарга язылам дип дәртләнеп йөри икән. Шуның өчен атлар алып, иярләр хазерләп кораллар җыеп маташа икән. Мена шуны әллә кемнәр күрсәткәннәр дә, инкыйлабка хәзерләнә дип тәукыйф иткәннәр. Янында бик күп корал тапканга, имеш, гаскари махкәмәгә бирәләр, ди. Шуның өчен анасының коты очкан, шуңарга ярдәм сорый.

Полковник бер гариза язу хакында кинәш бирде, фәлән итте, ләкин карчык

еглавыннан бушамады. Чиркәсчәләтеп, төрекчәләтеп, кычкырып-кычкырып еглап, тагы полковникның кулын упте. Аягына тезләнде. Тимергали бунын да исемен, фамилиясен язып адды. Белешергә вәгьда итте. Хатын тагы еглады, тагы көлде. Шул авыр хистән котылыр өчен Тимергали тизрәк һавага чыкты.

Күргәннәр, ишеткәннәр берлә башы казан кебек кайнаганга, ул, өенә кайтып йоклый алмаячагын хис итеп, акрынлап кына шәһәр буйлап китте. Анда да, бунда да подваллардан музыка тавышы ишетелде. Урамның һәр почмагында исерек эфисәр очрады. Урам буенда өзелмеәянчә атларда, автомобильләрдә марҗалар төяп кәеф-сафа чиккән эфисәр карваны өөелмәде. Шыр-шыр иткән марҗа тавышы кайвакытларны ботен шәһәрне тутырды. Ресторанның ачылып киткән ишегеннән тулып чыккан музыка, исерек тавышы доньяны тутырды. Ул шул тавыштан, шул сәфаләттән башындагы кадерле уйларны саклау өчен кечкена урамга борылды. Берничә адым атларга өлгермәде, хезмәтче марҗалар берлә йөри торган казачийларга, аның артыннан марҗаны тилертеп кычкырта торган солдат төркемена очрады. Анда-бунда ава-түнә килә торган солдатка, кычкырып йырлый торган казачийга барелде. Тагы борылып яктырак урамга чыкты. Уени чумып берничә минут китә алмады: «Полковник, полковник!» — диган тавышны ишетте. Әйләнеп карарга өлгермәде, ике ягына ике марҗа җитәкләгән бкр кызмача генерал килеп күреште:

— Таныш булыңыз, Мария Ивановна, Елена Петровна. Кая бунда ялгыз йөрисез, әйдәңез штабка, бөтен дуст-иш анда, сезгә, фронттан килгәннәргә азрак һава алырга кирәк,- диде. Шактый исереп өлгергән Елена Петровнаны Тимергалиевкә житәкләргә туры килде. Үзеннән-үзе штаб ресторанына кителде.

Генералнын ишеккә берничә мәртәбә чиртүенә ишек тар гына ачылды вә аннан әрмәнме, грузинмы — берсе башын тыкты. Боларны бер мәртәбә карап алганның соңында, танымаган Тимергалиевне күреп, аңа күз тегеп:

— Сезгә кем кирәк?— диде.

Генерал:

—Ул безнен берлә, безнең кунак!— дип түбән таба илтә торгам берничә баскычны төшеп югалды. Шаркылдап көлә торган исерек Елена Петровнага ярдәм итә-итә акрынлап Тимергали дә подвалга керде. Тар гына иттереп эшләнгән коридорның ике ягында тәсбих кебек итеп кабинетлар тезелгән иде. Алар эчләреннән чыр-чыр тавышлар ишетелә вә кайберләреннән русчалап йырлар, бию тавышлары килә, кайберләре караңгы мәсҗед кебек бум-бушлык хисе калдыра иде. Кунакдар тагы бер борылды, тагы бер буш булмәне үтте, ишек ачылды. Тимергалинең күз алдына электрик яктысына чумган зур бер булмә ташланды. Булмәнең уртасындагы өстәл өстенә дөньядагы бөтен төстә шешәләр тутырылган, анын төрле якларына төрле аш алды ашамлыклары, мивәлар түшәлгән иде. Югары түрдә Тимергалинең Порт-Артур иптәше генерал Петров угырган, аның ике ягына шәфкать һәмширәсе киемендәге егерме бишле, утызлы ике марҗа йирләшкән. Аларның күршесенә бер казачий генералы, аның күршесендә тагы бер буялган марҗа, аның күршесенә бер полковник, тагы марҗа, тагы полковник, тагы марҗа, өстәлнең түбәненә баягы интендант забиты, аның янына кызыл яңаклы яшь кенә бер жандарм киемендәге забит. Иң түбендә генә баягы номерда очраткан әрмәни утырган иде. Яңа кунакларга урын бирер өчен бар да сикереп торды. Генерал Петров кызарган күз.ләре берлә көлемсерәп:

— Бунда, генерал, бунда, полковник!- дип турдә урын курсәтте.— Танышыңыз, әфәнделәр, безнен атлы гаскәр каһарманы полковник Мирхәйдәр Батыргәрәевич Тимергалиев!— Полковник Мирхәйдәр шәфкать һәм-ширәсендәге хатыннарның кайсысының, княжна, кайсысының графиня икәнен белде вә ирләр арасында Петербургның аристократ гаиләсенең исемнәрен ишетте. Интендант забитны генерал:

— Бу безнен дамаларның сөйгән егетләре, безнең яшь әфисәр князь Оболенский!— диде. Аннан күчеп әрмәнгә: —Безнең гаскәргә әллә никадәр хезмәт иткән Карапет Карапетыч! Әфәнделер, бер-береңез берлә дустлашыңыз! —диде. Полковник Мирхәйдәр утырырга өлгермәде, Карапет шампанский шешәләреннән кадәхкә тутыра башлады. Кызмача бер хатын да аякка калкып:

— Безнен Форат елгасы янына кадәр илткән полковник Мирхәйдәр Батыргареевич икәнлегенә вә аның таза кулындагы рус байрагы Багдадка, Басра күрфәзенә кадәр җилбердәвенә әчәмез, яшәсен полковник!— дип кычкырды. «Ура!» — дигән тавыш бөтен булмәне алды. Тагы эчәргә тага хәйлә булды, дигән кебек, һәммәсе бокалларны төбенә кадәр эчеп бетерделәр. Берсе: «Музыка!»— дин кычкырды. Әллә кайдан музыкантлар килде. Әрмән, гөрҗи, азәрбайҗан көйләрен уйнарга тотынды, эчү китте. Исәнлегенә эчелмәгән беркем де калмады. Ахырдан ресторан хуҗасының саулыгына да кадәх күтәрелде. Исерү тирәнәйгәннән тирәнәйде. Кунакларның бик күбесе Тимергалиев берлә синле-минлелек өчен эчте. Әллә ничәсе килеп:

— Мин узем дә татар, бабай гына чукынган, әби генә чукынган. Татар халкы пакь халык, фәлән,—дип сөйләнде. Мәҗлес уйнады, көлде, йырлады, «у-у» килде. Хатыннар ачылды, әдәп качты. Фәкать Мирхәйдәр генә исермәде. Ул иптәшләре кадәр эчсә дә, әллә ник исереп китә алмады. Бунда рус гаскәре арасында булса да, бая гына күргән кешеләр, манзаралар буньң күзеннән китмәде, шуларнынң әрнүе, сыкрануы үзен-үзе оныттырмады, ул Тимергали булып калды. Күзенең очы берлә генә карап Карапет Карапетычның да тәмамән айнык икәнен күрде, аның айныклыгыннан көнләдеме, әллә шул әрмәнинең бөтен шул зур мәҗлесне идарәсеннән хурландымы, аңарга каршы җирәнү, хурлану хисеннән мөрәккәб бер авыр хис биләде. Берсе эчеп, берсе көлеп, берсе йырлап маташканда, ул һичбер вакыт үзенең авыр хисләреннән котыла алмады.

Менә берсе: «Кызлар!» — дип кычкырды. Озакламады, балалайкалы музыкантлар берлә алты-җиде яшь кыз кереп биергә тотынды. Бу кызларның араларында картаеп килә торган, йөзен-ниен буяулар берлә төзәткән кызлар булганы шикелле, унөч-ундүрт яшьлек кызлар да юк түгел иде. Халыкның бертуктамаенча кычкырулары, кызларны эчереп-ашатып әвәрә булулары арасында, Мирхәйдәр Карапет Карапетычның ике яшь кыз берлә төрекчә сөйләвен ишетте вә бик тиз ике кыз «Зәйбәк» биюен башлады. Эчу, кычкыру, уйнау, көлү арасында Мирхәйдәр теге кызларның берсен чакырып:

— Син Төрек кызымы?— дип, төрекчә сөйләшә башлады. Кыз элгәре курыкты, болардан әллә кемне күзе берлоә эзләде.

— Әвәт, төрек кызы, без бунда әрмәннәрдә торамыз. Без дүрт кыз, фәкать әман, бәкем, сөйләмә! Бези олдурерләр, һәркөн дуйорләр!— диде. Качарга тырышты. Мирхәйдәр аларның кая торуларын сорады.

— Валлаһ, бәкем, белмиорем, иштә утуртийорләр арабая, гитрийорләр, соңра гидийорез, һәркөн буйлә, беремез хаста дүште,— диде дә, әллә нидән куркып бик тиз качты.

Ата угылын, ана кызын белмәс дәрәҗәгә килгәндә казачий генералы торып: «Төрек маршы уйна!» — дип кычкырды. Карапет Карапетычның: «Генерал, ничек дошман маршын уйныймыз?»— фәлән, диюенә: «Уйна! Мин синең авыз-борыныңны ватармын! Син кем бунда? Миңа сабак өйрәтергә, армянская морда!.. Уйна!»— дип кычкырды. Хатыннар да, төрек маршы, диделәр. Берсе торып, төреклернең джетельменлеге хакында сөйләде, берсе үзенең төрек нәселеннән булуын дәгьва итте, берсе:

— Шул эт угылы этләр, әрмәннәр безне төрекләр берлә бозыштырдылар. Алтын кебек халык!— диде. Орду маршы башланды. Бөтен исерекләр «ду» килеп, кайсы кул чапканда, кайсы: «Браво!»— дип кычкырганда, Мирхәйдәр күзе берлә төрек кызларын эзләде. Аның берсе, бераз эчеп-исереп алган да мәгьнәсез итгереп көлеп тора иде. Берсе дивар янына сөялгән дә күзеннән мөлдер-моөлдер иттереп яшен агыза иде, кем белсен — ни өчен бу сәфаләт җариясе яшь түгә иде? Тагы бер марҗа, төрекчә бер йыр-фәлән, диде. Тагы кычкырыш, тартыш китте. Теге әрмән тагы кызлар берлә әллә ни сөйләде. Шуннан теге көлеп тора торган кыз алга чыгып басты. Музыка туктады. Исереклер да бераз басылды. Кыз саф тавыш берла французча «Марсельеза»ны йырлады. Исерек компаниясе аптырап калды. Инкыйлаб маршына каршы бер кыйсьме протест итмәкче булды, бер кыйсьме тыңламакчы булды, берсе көлмакче булды. Төрек кызы күзен бераз йомып йырлавында дәвам итте. Йыр беткәч һәркем кул чапты. Бер княжна французча итеп кыздан сорашмакчы будды:

— Син кем, кайдан, кем кызы?

Кыз кызарды... Французча:

— Мин бер төрек кызы,— диде дә югалды... Мирхайдәрдә бу «Марсельеза», төрек кызы авызыннан төрек йыры дип йырлаткан «Марсельеза» чуалчык бер хис уятты. Кызның берәр зуррак гаиләдән икәнен аңлатса да, бая орду маршы уйналганда еглаган кызга караганда рухан тәмам башкалыгын күрсәтте. Тавыш-туыш, эчу- исерү туктамады, йыр, музыка дөньяны алды. Менә, бердәнбер полковник: «Бомбардировка!»— дип кычкырды. Үзе зур шампания шешасе берлә почмактагы көзгегә бәрде. Көзге чылтырап, ватылып төшерга өлгермәде, икенчеләре икенче шешәләрне, өченчесе тагы берне, дүргенчесе тагы берне ыргытты. Дивардагы көзге туктамадан шалтыр-шолтыр ватылды, шешәләрдәге шәраблар ягьмур кебек яуды. Булмәда ары-бире шешә очып йөрде, барып төшеп ватылды, чартлады, ватылу-коелу берлә дөнья тулды. Шуңарга хатыннарның чыр-пыр килүе катышты. Ватылачак шешәләр беткәч, теге полковник кадәхләр берлә атты. Аның артъннан башкалар тотынды, кадәхтән соң тәрилкәләр китге. Өстәл өсте бер минутта идәнгә төште. Бөтен идән ватык тәрилкәләр, калдык ашлар, мивә кабыклары берла капланды. Шешәләрдән аккан эчемлекләр берлә идән елга булды. Берсе: «Ура!»— дип кычкырып, хатыннарны тотты. Бер генерал бер төрек кызын муенына атландырды. Берсе бер яшь кызны сарык салган кебек иңсәсенә салды. Бер полковник княжнаны кулына күтәрде, аның чәче тишелеп төште. Ике әфисарнең кулына бер хатын утырды. Берсе алга чыгып: «Раббем, гафу ит!» — дип, дини бер христиан гыйбадәт көен жырлый башлады, аңарга икенчеләр кушылды. Аның артыннан «Алла, падишаһны сакла» кое башланды. Шәм күтәреп килгән ресторан хуҗасының битенә бер полковник зур савыттан алып гәрчис буяды. Берсе, ватылмый калган борыч савытыннан борыч сипте, берсе колагына тоз тутырды. Аның төчкерүеннән, йөткерүеннән көлә-көлә, йырлый-йырлый мөсафирлар кузгалды. Мирхәйдәр Тимергали дә тавыш-туыш арасында төрек кызларының кая киткәинәрен күрми дә калды. Халык кайсы анда, кайсы бунда таралды. Кабинетлар яңы мөсафирлар берлә тулды. Тимергали ишектән чыкканда, күршесендә фәкать карт казачий генералын гына очратты.

* * *

Баш команданның сараена полковник Тимергалиев килгәндә әле беркем дә юк иде. Явер аны озын остәл куелган, тирә-юньнәре гтөрле хариталар берлә тутырылган зур бер залга кертте дә: «Хәзер, полковник, бар да киләчәкләр!»— дип чыгып китте. Ялгыз калган полковник, өстәл тирәсенә куелган урындыкларны, алдына куелган кәгазьләрне, каләм, кара савытларны күздән кичереп, гаскәри мәҗлес шактый зур булачак икән дигән фикергә килергә өлгермәде, дивардагы зур сәгать бик һаваланып кына 11 не сукты. Мирхәйдәр бүгенге гәзитәдә күзен йөртә башлады. Бер яңы хәбәр юк. Һәр йирдә тынычлык, ләкин алманнар бит гадәт буенча һәр елны язга таба бер хәрәкәт башлыйлар. Безнекеләрнең берсена бик каты бер йомрык оралар, үзләренә яиса иттифакчыларына яңы бер майдан ачалар. Үткән елны шул вакытны Карпатта ясаганнар иде. Кавказ жөбһәсендә шул йомрыкны жыя торганнардыр да, халкы төрек, дине мөселман булган Кавказны басмакчы була торганнардыр. Чынлап та шулай итәргә бик мөмкин бит, ул зур харитадагы нокталарны карап, үзен төрек пашасы, төрек әркяне хәрбия забиты кебек иттереп уйлады. Шундагы юлларны, тауларны, елгаларны барысын да күздән кичерде. Барысының да никадәр гаскәрне туктата белүләрен хисаплады. Гаскәрнең ничә көндә, ничә атнада утә беләчәк мәсафәләрне исәпләде. Рус гаскәренең куәтен бизмәнгә салды.

...Мин йөз мең, юк, йөз егерме меңле төрек гаскәре — солдаты берлә өч айда бөтен Кавказны үтә алыр идем... Шуннан соң Кавказдан арымаган йөз мең атлы гаскәр, ике йөз, өч йөз мең жәяуле гаскәр жыеп алып, Ингел- терәне Басра күрфәзенә себереп түгәр идем... Чынгызча иттереп бер хәрәкәт ясап, шимали Иран, Хәзәр диңгезе аша утеп, Төркстанга барып керер идем. Идел буйлап Казанга кадәр менеп, Алтын Урданың нигезен корып, урыс

ягыннан Иделгә ага торган елгаларның коюларына сакчылар куеп, бетен Идел буена. Хәзәр диңгезенә хужа булыр идем. Аннан?.. Аннан?..

Аның фикере бер ноктага туктады. Ул Төркстанның халкы, байлыгы хакында уйларга, күпме гаскәр жыеп булу хакында төшенергә кереште... Әйе, мондагы шәһәр халкы гаскәрлекне оныткан, ләкин ул берни түгел... Анда анадан тума атлы гаскәр, төрекман, кара кыргыз, казакъ яши. Шуның узеннән генеә чыккан көч берлә төн ягыннан килгән урыс көчләрен туктатып була. Идел буйлап менеп татарны, нугайны русның аркасыннан аякландырып Себерне, Уралны кисеп була. Идел-Урал, Себер, Төркстан, Кавказ киселсә, Русиянең фабрика, заводы кайдан материал ала, ни эшли? Русиянең эендәге ихтилял фикере, түрәләрендәге ришвәтчелек, гаскәрләрендәге исрафчылык көя булып эченнән ашый, Русия шул зур йомрыкларга чыдый алмый, жимерелә... Тагы рус-төрек тартышуының икенче бите ачыла. Әдернәдән апып Кашгарга кадәр бербуйдан тезелеп киткән төрек халкы, алтмыш- җитмеш миллионлы төрек халкы берлешә, тагы үзенең тарихи дошманына - русларга каршы бер байрак күтәрә... Әлбәттә, бу сугыш, бу тартыш бер елда бетми. Әлбәттә, бундагы биш-алты йөз еллык мәсьәләләр бер кылыч кисуе берлә хәл ителми... Ләкин Аксак Тимернең ясаган хатасыннан туган бөек Русия жимерелә, бөтен дөньяны тотарга дип канатларын ачкан кара кошның канатлары киселә, ул элгәреге хеленә, үзенең мәскәвиясенә кайта...

Төрек әркяне хәрбендә шул план булырга тиеш! Чөнки бу план госманлы тарихының бу көнгә кадәр киткән хата, яңлыш юлыннан чыгарачак, кырык кора- мадан корылган госманлылык императорлыгы йиренә бер милләттән оештырылган төрек дәүләте мәйданга китерәчәк... Алмания әркяне хәрбе дә бу фикердә ярдәмдә булырга тиеш, чөнки аның сатуына, һөнәренә дуст бер мәмләкәтнең, химаясендә дөнья кадәр базар майданга киләчәк. Үзенең ракыйбе Ингелтерәнең һөнәр сәнәгатен, тиҗаратен мәгълүб итәчек. Шулай булганда ни дип Әнвәр паша Суәеш каналы буенда маташа? Ни дип бундагы төрек иллереннән алынган гаскәр берлә, төрек илләрен дошман кулында калдырып, Мисырга керергә, Африкагаа жәелергә тырыша!.. Ник андагы гарәп гаскәрен монда китереп Кавказга, Иранга ташлап, бундагы төрек илләрен, эч күнелдән истикъляльга омтылып торган төрек йортларын котылдырырга ашыкмый?.. Ник бундагы куәт берлә файдаланырга теләми?..

Фикер тәмам булып бетмәде, ишек ачылды: эре ак тешле, ач яңаклы, озын буйлы, имансыз күзле, гаскәри киеменнән бер инглиз килеп керде. Явернең полковник Тимергалиев, полковник Вильямс дип күрештерүләренү әһәмият бирмәгән кебек, сәгатькә күзен йөгертте. Өстәл тирәсендәге бушлыкны күреп гаҗәпкә калган кебек кыяфәт алды. Тимергалиев инглизчә әлләниләр сөйләде. Явер: «Полковник французча, алманча гына сөйли»,— диде. Инглиз күзен текте. Инглизчә дә белми торган полковник ничек иттереп гаскәр идарә итә алсын, ул ни дип бундый мәҗлесләргә чакырыла дигән кебек хәйрәтен йөзенә чыгарды. Бер урындыкка утырып, икенчесенә аягыны куеп, чантасыннан әллә никадәр комаш үрнәкләре чыгарды, аларны өсталгә җәеп салды. Бер кәгазьгә шуларның номерларын, хисапларын яза башлады. Кайвакытлар туктап хисаллар эшләде. Үзеннән- үзе сөйләнде. Тагы хисаплады, тагы язды, торып китеп зур харитадан Ирандагы шәһәрләрнен Басра курфәзенә мәсафәсен үлчәде. Бакуга, Әнзалигә юлларны карады. хисаплады, үлчәде, язды. Шул коммивояжерны күреп, Тимергали аптырап калды: «Менә шулар өчен сугышамыз, күрәсең. Менә мин шуның мал-товарының юлы уңайлансын өчен, курәсең, төрек каны түгәм»,— диде. Узе дорфа йөзле шул инглизнең йөзендә, күзендә берер мәгънә аңлар өчен эзләнергә тотынды. Тупас, үзсүзлелеккә башка бернәрсә таба алмады.

Ишек ачылып китте, этәч кебек пөхтә, этәч кебек җанлы бер француз килеп керде. Ул үзенә көләчлек биреп, инглизнең янына килеп, инглизчә сөйләде, көлде, елмайды. Инглиз һаман «Олрайт, олрайт! (all right) диюгә башка бер сүз әйтмаде. Француз Тимергалигә килеп амың кулын кысты. Французчалап:

— Мин сезне күптән ишетә идем, фәлән,— дип, нәзакәтлелек сатарга кереште вә бик тиздән:

— Белесез, куланил, алманнар, бөтен дөньядагы шулкадәр мәшәкать берлә майданга килгән мәдәниятне бетерер өчен бөтен көчләре берлә тырышалар. Төрекларне дә үз тарафларына аудардылар... Бөтен мөселман дөньясы бу мәсьаләдә төреклергә хилаф. Һиндстан мөселманнары әллә никадәр куңелле гаскәр бирделәр. Безнең Жәзаир, Тунис, Фәс әллә никадәр куңелле гаскәр чыгарды. Ченак кальгада, Гыйракта, Македониядә төреклергә каршы һинд вә Африка мөселманнары сугышып ята. Бу якта Русия мөселманнары сугыша. Бу курсәтә ки, кәнж төрекләрнең германо-филлык сәясәтләре тугры түгел. Без төрекләрнең дошманы түгел, без хәзерге хокүмәтнсң дошманы. Бу мөселман дөньясы өчен зарарлы дип уйлыйбыз. Куланил, белесез, бездә мөселманнар элгәреге үз тормышларына караганда әллә нича мәртәбә шәп торалар, көннән-көн француз мәданиятена якынлашалар. Мин Жәзаирда, Туниста булдым. Мәктәпләрдәге балаларның Лафантен шигырьләрен сөеп укуларын куреп исем китте.— Французның, очсыз-чиксез сүзләре бетмаде, Мирхайдәр һичбер төрле җавап бирергә өлгермәде, кичәге казачий генералы килеп керде. Нә французча, нә инглизчә белмәгәнгә, инглизнең күзен акайтып каравына да көлемсерәде, французның бик күп нәзакатләренә да елмайды. Берсе артыннан берсе башкалар да килеп, сагать уникегә таба халык җыелып бетә язды.

Инглиз да үрнакләрен чантасына тыкты. Һәммәсе йирле-йирена утырды, күршеләре берлә сөйләү башланды. Әркяне хареб рәисен көтеп торганда, ишек ачыдды, урта гына яшьле бер хатын килеп керде, һәммәсе сикереп торды. Берәм-берәм барып хатынның кулларын үптеләр. Полковник Тимергалиевне дэ тәкъдим иттеләр. Хатын французча иттереп:

— Сез минем иремне көтә торгансыздыр, ул хәзер килә. Мин аны азрак борчыдым, гафу итеңез. Бунда мәҗлес тәмам булгач, һәммәңезнең безгә ашка килуеңезне утенәм!— диде. Янына җыелган генералларга, полковникларга русчалап: «Вася хәзер килә, безнең Мубсик (эт исеме) авырып китте, шуңарга доктор чакырттым да, ул шуны көтеп калды, хәзер килер»,— диде.

Сәгать бергә чирек калганда генерал килде, мәҗлес башланды. Әркяне хәреб куланиле Фон Матһаим Кавказ жәбһәсе хакында французча гомум мәгьлүмәт бирде. Аны инглизчәга бер полковник тәрҗемә итте. Казачий генералы, тагы бер фирка команданы, бер полковник: «Русчага да тәрҗемә ителмәсме, без аңламадык», —дисәләр дә, рәис: «Сез үз кешеләр, ахырда сөйләшермез»,— диде. Мөзакәрә башланды. Гомум мәсьәлә хакында мөзакәрә бетмәгән нде, инглиз сүз алды. Әһәмиятле мәсьәлә — Багдадка инглиз гаскәренек йирләшуедер, шуның өчен бу тарафтан тизрәк төрекләрне кысрыклау лаземлеген, инглиз-рус жәбһәсе берләштерелүенең иң кирәкле эш икәнен аңлатты. Инглизләрнең соң елда Иранда никадәр сәүдәләре кимүен рәкымнар берлә күрсәтте вә эш болай дәвам итәчәк булса, инглизләрнең зур зарарга очрауларын вә иттифак исеменә русларның үз вазыйфаларын тизлек берлә кылулары кирәклекне исбат итте.

Шуннан соң әркяне хәреб рәисе кыска гына җавап кебек бер сүз сөйләде һәм дә рус әркяне хәрбенең шундый бер план ясаганын аңлатты. Бер полковник торып, гомум рәвештә хәрәкәт ни төсле булачакны, полковник Тимергалиевнең бүлегенә шул вазыйфа йөкләнелгәнен аңлатты. Әркяне хәреб рәисенең әмере берлә, Тимергали планның вакларын, тәфсыйлатын аңлатыр өчен аякка калыкты. Французча да, инглизчә дә белми торган, баядан бирле иснәп тора торгам генераллар, полковниклар бердән: «Русча сөйлә, полковник, русча!»— дип тавышландылар. Рәис кунакдарньң хөрмәтен сакларга маташса да, ахырдан, инглизчә тәрҗемә итсәлер дип, русча кабул ителде. Тимергали мәгърузәсендә харитадагы бик күп нокталарга тигәнгә, таулар, елгалар, шәһәрләрне сөйләгәнгә, бөтен сүзләр жәгърафия дәресе, кебек булды. Француз бик дикъкать берлә тыңлады: харитада сызыклар ясады, ишарәләр куйды. Ләкин инглиз буңарга мөнәсәбәте юк кебек һичбер әһәмият бирмәде. Урыслар башларын саллап-саллап тынладылар. Инглизчәгә тәрҗемә китте. Тәрҗемәдән соң инглиз:

— Полковникның сүзе хыял, ул дурт-биш йөз километрлык йирне ике-өч атнада утмәкче була, бу тарихта күрелгән нәрсә түгел, — диде.

Тимергали:

— Балкан сугышында Әнвәр паша атлы гаскәр берлә көненә житмеш биш километр йөрде, ике тәүлектә Әдернәгә барып керде. Үзем япон сугышында алтмыш километр йөрдем. Минем гаскәрем — төрек гаскәре, төрек гаскәрен Аурупа гаскәре берлә үлчәргә ярамый. Аның тамагы тук, өсте бөтен булса, аның алдында һичбер манигъ юк, — диде. Инглизчәгә тәрҗемәдән соң инглиз кызарды, бүртенде, тагы торды:

— Безгә фәлән юл ачык булырга кирәк. Безнен сәудәмез туктады. Аннан соң, полковник Тимергалиевнең барырга теләгән йирләре — ул инглиз минтакасы. Могаһәдә буенча, Төркия бүленгендә ул йирләр безгә булырга тиеш. Без сезнең гаскәрне Кара диңгез буйлап алга җибәрелүен һәм дә Ирандагы безнең артымызны саклауны кирәкле табамыз. Тагы Багдад юлында безгә каршы Алмания әсирләреннән җыелып килгән татар гаскәре сугышып ята. Сез тагы шуларга ярдәмгә бер татар генералы җибәрергә буласыз. Мин моны аңламыйм, — диде...

Тимергали сикереп торды. Рәис аны йомшартырга теләсе дә булдыра алмады. Французча иттереп җавапка кереште:

— Без монда — гаскәри бер мәҗлестә. Гаскәр вә сугыш эшләрен гаскәри фән ягыннан тикшерәмез. Без бунда бер тиҗарәтханәнең конторында түгел. Гаскәри эшләрне фәлән сәудәгәргә файда, фәләненә зарар ноктасыннан карый алмыймыз. Инглиз сатучыларының зарарлары булырмы, файдалары чыгармы, бу безнең хисапка керми. Икенчедән, Русия мөстәкыйль бер дәүләт, ул сугышка мөстәкыйль булып керә, аның узенең аерым әркяне хәрбе бар. Аның үз гаскәрен идарәгә башлыкны теләсә кемне куярга хакы бар. Һичбер вакыт Русия әркяне хәрбе гаскәри вазыйфаларын берсенә йөкләткәндә инглиз коммивояжерларының фикерен сорамаячактыр, — диде вә шул «коммивояжер» диган сүзне бер-ике мәртәба тәкрарлады вә инглизнең йөзенә, күзенә тутырып карады.

Француз сикуреп торды, Тимергалиевне мактады, инглизнең сүзен тәфсир итте. Руслар да тордылар, икегә бүленеп кайсы русча, кайсы французча сөйләргә тотынды, инглиз генә кыяфәтен үзгәртмәенчә, миңа гаид түгел кебек хәлендә калды. Рәис кыңгырау шылтыратты, тыңлаучы булмады. Тимергали ачыктан-ачык теге инглизне дуэльгә чакыртыр өчен, жаһил коммивояжер, фәлән, дип французча сүгенүендә дәвам итте. Мәҗлес «ду!» килгәндә ишек ачылды, тагы графиня керде: «Әфәнделәр, шулпа суына, зинһар рәхим итеңез!»— диде. Рәис та шуны көткән кебек мәҗлесне япты: «Ашка!»— диде. Һәркем аякка торды. Графиня тавышланганны күреп: «Ни тавышланасыз, безгә солых кирәк, солых! Солых ясау хакында сөйләшеңез!.. Сугышка без хәзер бөтен хатыннар, императрцадан башлап авыл хатынына, керче хатынга кадәр хилаф! Солых, югыйсә, Русия харап булачак... Инкыйлаб... Фетнә... Жомһурият...»— диде. Тимергалине йомшартырга теләгон француз куланиле Тимергалидән графиняның кем вә нинди гаиләдән икәненә сүзен борды. Тимергали ярты тавыш берлә: «Графиня — императрицаның якын фрейлине, баронесса Вольф!»— дип жавап бирде. Француз: «Эм-м!»— диде, һәммәсе аш бүлмәсенә акты.

* * *

Кичке мәҗлес бик озын сөрде. Бик күп мәсьәләләр алга куелды. Киләчәктә алга таба баруның киң планы кабул ителде. Тимергалинең атлы гаскәренә, элгәре уйланган кебек, Төрек жәбһәсенә ярым инглизләргә барып кушылу йөкләтелде ва шул эштә аңарга киң сәләхият бирелде. Күршесендәге фиркаләр берлә мөнәсәбәтләре тәгайен ителде. Ахырдан гына бу планны эшкә ашырыр өчей кирегә кадәр гаскәрнең коралы җитеп бетмәгәнгә, һөҗүмнең көне тәгайене әркяне хәрбенең карамагына тапшырылды. Француз куланиленең:

— Язга кадәр мотлакан бер хәрәкәт ясалмаса, алманнарның тагы бер мәртәбә Париска таба һөҗүмнәре көтелә, шул хәрәкәт тизрәк башланылсын,—дигәненә дә зур кыйммәт куелды. Тимергали кулындагы хариталарына Русия гаскәренең торышының бөтен планын, корал, гаскәр мәркәзләренең йирләрен ишарә итте. Кавказ жәбһәсенә килә беләчәк куәтләрне хисаплады. Французларның, үз жәбһәләре хакындагы фикерләрен, инглизлернең

Гыйрак жәбһәсендәге мәгълүматларын туплады. Моңынча төрек әсирләреннән җыйнаган мәгълүмат кебек дикъкать берлә туплады.

Мәҗлес тәмам булганда, әркяне хәреб рәисе:

— Әфанделер, күрәсез, мәсьәлә бик зур. Алдымызда Русиянең иң зур тарихи бер бурычы тора. Бөек Петр заманасыннан бирелеп тә, үтәлмәгән милли, дини вазыйфасы тора. Русиянең әлегә кадәр бөек Русия булып яшаве өчен аның юлына каршы чыккан шул Төркияне уртадан калдырырга тиеш! Аның авыру тәне алып ыргытылып, Русиянең теләгәнечә киңәюенә һичбер төрле унайсызлык ясамаска тиеш! Иттифакчыларымыз берлә киңәшләшеп, Төркия тәкъсим ителергә карар ителде. Бизанес императорының чын варисы булган Русияга Әрмәнестан, Истанбул вә бугазлар вәгъдә ителде. Рус халкының дине, милләте өчен алты йөз елдан бирле алдына чыккан төрек халкы берлә тартышуы соңгы баскычына басты... Төрекләр тарафыннан былчыратылган Айа Суфияның пакьләнүе, буннан биш йөз ел элек аның башыннан төшерелгән салибның яңадан тагу шәрәфе безга тапшырылды. Мин сездән динеңез, милләтеңез, императорыңыз өчен, шул мөкатдәс тарихи хезмәттә бөтен фидакярлекләрне көтам. Яшасен император, яшәсен аның каһарман гаскәре, саллансын Истанбулда Русиянең ике башлы кара кошлы байрагы! Ялтырасын бөтен дөньяга Айа Суфияның башындагы мөкатдәс салибы!— диде.

Бөтен руслар кул чапты, ура кычкырды. Бер казачий генералы күзеннән яшьләрен агызды. Француз да шул җанлануга катышты, ул да: «Виф ля рус, виф ля имперер!» — дип кычкырды. Инглиз генә, миңа гаид түгел, дигән кебек суык калды. Тимергали шул һәяҗанда үзен-үзе тәмамән ят хис итте, үзенең кем икәнлеген, үзенең нигә хезмәт иткәнен беренче мәртәбә ап-ачык итеп күрде.

Зур тавыш-туыш арасында эчендәге хисләрен саклау авыр булмаса да, элгәреге кебек иптәшчә иттереп шул генераллар, полковниклар берлә мөнәсәбәтне дәвам иттерү читенләште. Ул тешен кысты, көчен җыйды. Алдындагы мәсьәләләргә утте.. Әркяне хәреб рәисенә барып:

— Минем гаскәрем торган йирдә бөтен халык төрск. Ирләр үлеп, качып беткән. Калган хатын-кыз, бала- чага бик ач булганга, гаскәргә комачаулый, казарма тирәсен сырып ала. Безнең солдатлар, беләсез, төрекмән, кыргыз, комык. Болар бу хатын-кыз, бала-чага берлә бик тиз аңлаша ала. Аларга каршы әрмән күнеллеләренең, безнен казачийларның иткән җәберләрен бик авыр күтәрә, күптән түгел бер авылда шул төрек бала-чагасы хакында безнекеләр берлә әрмән күнелләләре арасында тәмам сугыш булды. Ун-унбиш әрмән үтерелде. Бездән биш-алты кеше яраланды. Шуның өчен ул йортсыз-йирсез бала-чаганы, хатын-кызны бунда, тылга күчертергә миңа рөхсәт биреңез! Начальник сөйләп бетергәнне дә көтмәде:

— Ничек теләсәңез, шулай эшләңез. Сезгә, полковник, киң ихтыяр! — диде. Үзе сәгатенә карап:

Миңа кайтырга вакыт, графиня көтә торгандыр! — диде. Полковник янындагы кятибкә күрсәтеп:

— Димәк, мин кирәкле кәгазләрне канцеляриядән алырмын?

— Рәхим итеңез, рәхим итеңез!.

Тимергали яшь кенәз явер Оболенскийны табып, аньң төймәсеннән тотып, мин синең ни эшләгәнеңне беләм икән кебек иттереп, күзенә тугры карап:

— Кенәз! Сез бит минем торган номерның телефонын беләсез?

Кенәз кызарды:

— Әйе, әйе,— диде.

— Сез белесез, минем бунда әллә никадәр эшем, миңа тиз китергә дә кирәк. Эш шуны тели... Миңа телефон берлә генә бер хезмәт итеңез әле!— диде. Кызарган, буртенгән кенәз мәсьәләнең шулай җиңел бетүен аңдагач:

— Рехим итеңез, рәхим итеңез, әмер итеңез!— дип җавап бирде. Полковник хатирә дәфтәрен чыгарды вә кичәге ике мәсьәләне аңлатты.

— Боларны мин сораштым, һичбер сәяси ягы юк. Болар һәммәсе аңлашылмаудан килгән нәрсәләр генә. Миннән якын танышларым үтенделәр. Шуларны, мөмкин булса, чыгарыңыз, булмаса, эшләрен җинеләйтеңез. Берсе бер сәудәгәр икән. Арада бер акча эше дә булырга кирәк: — диде һәм дә тагы кенәзнең күзенә карады. Кенәз:

— Баш өсте иртәгә үк бөтен мәгълүматны җыярмын, кулдан килгәнен һәммәсен эшләрмен, телефон берлә сезгә хәбәр бирермен, —диде...

Мәҗлес тәмам булып, урамга чыкканда Тимергали үзендә әллә нинди бер җиңеллек хис итте. Озак көннәр юлда калып, керләнеп беткәннең соңында мунча чабынып чыккан кеше кебек тынычланып китте. Озын көтелгән куркынычлы мәхкәмәдән аруланып чыккан кебек пакълек, сафлык хис итте. Тамырында каннар тазардымы, тәмаман яшәреп киттеме, күңеле көрәйде, дәрте артты, алдагы әллә нинди томанлы идеалга таба ул яшь егет кебек омтыла башлады. Күптән хәл ителгән кебек иттереп телеграфка борылды. Вакытның соңлыгына карамаенча, кызына:

«Хәзер миңа килергә юлга чык, Тифлистә бөтен кирәкле кәгазьләрне Улмәс угылында табарсың, бик көтәм»—дип язды вә тиз иттереп түләп җибәрде. Рухында тагы бер жиңеләю хис итеп, өенә борылды.

Бүлмәсендә әллә никадәр визит карталары, хатлар, гәзитәләр дә булса да, берсен дә укымаенча шул зур көндә үткән вакыйгаларны, сүзләрне, карарларны тикшерер, жентекләп, иҗекләр өчен урынына сузылды. Баштан башлап, тагы бер мәртәбә фикерен тикшерергә теләсә дә, башы соңгы карарыннан үтмәде. Җитте! Уткәннәр үтте, кичкәннәр кичте, бүген Мирхәйдәр Тимергалиевнең тормышында бер тыныш куелды, аның юлы борылды. Моңанчага кадәр барганынын томам тискәренә борылды. Ул үзенең урынын кая икәнлеген бүген ачык белде, үзенең юлын тапты. Инде сөйлисе, уйлыйсы калмады, инде эшлисе, гамәлгә куясы гына калды. Ул шул юл табуыннан шулкадәр кәефләнгән иде ки, үзен-үзе яңа туган биләүсәдәге бала кебек хис итә иде.

Икенче көнне полковник Тимергали көн буе кәнсәләриядән кәнсәләриягә чапты. Ятим төрек балаларын, тол хатыннарын китертер өчен кәгазьләр алды. Тимер юлына рөхсәтләр чыгартты. Шул эш өчен үзе берлә бергә бара торган доторга вә аның иптәшләре дурт-биш кешегә шаһәдәтнамаләр ясатты. Кызының жәбһәгә баруы өчен кирәкле кәгазьләрне хәзерләтте. Үзенең гаскәре өчен җитешеп бетмәгән кием-салымны, коралны ул күзе бнрләттимер юлга җибәртте. Хәзинәдәге забитларның мәгаш акчаларын алды. Үзе өчен кирәкне-яракны туплады. Штабка кереп Кавказ фронтының соңгы тәфсилле харитасын алды. Штабның төрекләр хакында җыйнаган мәгълүматлы яшерен китабын да кулда итте. Башлыклары берлә аерым-аерым күреште, алардан һөҗүм планы, һөҗүм нокталары хакында, гаскәрнең күпме җыелуы хыкында  иң серле магълүматне туплады. Кичкә таба гына арып кайткач, Арыслан Үлмәс угылына, телефон сугып, саубуллашырга юнәлде. Анда аны тагы шул ук сөемле гаилә каршылады. Теге ябылганнарга иткән ярдәме, ятимнәргә иткән хезмәте өчен рәхмәт укылды. Тагы шул гаилә эчендә сизмәенчә бөҗен кичен үткәрде.

Китәргә дип күрешергә торгач кына ул:

— Онытканмын икән, минем сездән тагы бер үтенечем бар. Минем кызым берничә көннән шафкать һәмширасе булып минем яныма барыр өчен Тифлискә киләчәк, аныә кәгазьләрен сездә калдырыйм. Яшь кыз, тажрибасез, шуңарга ярдәмда булыңыз!— диде. Әсмабикә да, кызлар да бу сүзне бик сөенеп каршы алдылар вә мотлака үзләренә төшәргә чакырдылар. Тимер юлга чыгып каршы алачакларын сөйләделәр. Мәсьәлә хәл ителде дигәдә генә, Фәридә көтелмәгәндә:

— Мин да барыйм, полковник, мине да алыңыз!— диде. Үзе да шул ят фикердән кызарып китте. Тимергали:

— Ул бит, безнең йир — сугыш эче, иртәга ни булачагын бүген белеп булмый. Ул кызлар йори торган йир түгел, — диде. Әсма да, адвокат та:

— Юк, болай гына сөли, фәлән, - диделәр. Фәридә:

— Чынлап әйтәм, полковник, сезнең кызыңызга барырга ярый бит. Ник миңа ярамый? – дидею Тимергали:

— Минем кызыма да ярамый, ләкин мин бит үзем анда. Кызым шәфкать һәмширәсе дигән бер яңлыш фикерне башына суккан, шул юлда харап булмасын дип, үз яныма чакыртам. Анда кызларга түгел, ирләргә дә кызыгылы торган нәрсә дә юк. Анда бит ут ыжгыра, үлем уйный.

Фәридә этисе-әнисенә:

—Барыйм инде, әни, мин озак тормам, шундагы хәлне күрермен да кайтырмын. Полковник, рөхсәт итеңез, мин дә сезнең кызыңыз берлә бергә барыйм? — диде. Тимергалинең мангаеннан тир чыкты, ул:

— Мин кызым янында сезнең кебек тәрбияле бер туташның булуын бик теләр идем, ләкин беласез, туташ, ул сугыш асты. Бүген әмер килсә, без бүген ут эчендә.

Сугыш хатынны-кызны, бала-чаганы аермый. Анда шәфкать, мәрхәмәт юк, анда үлем, кан. Шунда ничек сезгә барырга рөхсәт итим? Әсма да, Арыслан да:

— Юк, юкны сөйли, фәлән, — диделар. Лакин Фәридә үз фикеренда калды:

— Ник сезнең кызыңызга ярый да, миңа ярамый? Сугыш булса, яралыларны карармын, кем булса да бит сезнең гаскарда төрек баласы. Полконник:

— Сез дә урыс өмәсенә керәсезмени? — диде. Фарида кызарды, бүртенде, җавап таба алмалы. Ахырдан:

— Юк, кермим, мин үз халкыма хезмат итәргә, үз халкымның ярасын юарга, җәрәхәтен бәйләргә барам. — диде. Полковник тагы:

— Җәбһәгә бит кызыл тәре һәмширәсе булмаган бер хатын-кыз да жибәрелми, сез һәмширә түгсл. Фарида:

— Булам, берни түгел, булам! — диде. Арыслан берлә Әсма аптырап калдыдар. Полковник:

— Соң сез, куңелеңездә бу кадәр милләтчелек ташы торган бер кыз, мөселман тәрбиясендәге бер туташ, кукрәгеңезгә шул кызыл тәрене тагарга ничек разый буласыз? - диде. Фәридә тагы аптырады, кызарды. Ахырдан, белемсез, фәлән, дип озын сүзга кереште.

Шуны карап тора торган Ибраһим:

— Юк, бу сүзләр барда ялган сүзләр. Син милләтчеме? Милләтче! Үзеңнең, милләтеңнең, динеңнең дошманлык галәмәте булган тәрене син, акмы ул, кызылмы ул, ничек күкрәгеңа тага аласың?

Фаридә:

— Юк, такмыйм, ул форма гына, ул тышта гына кала, фәлән,— диде.

Тимергали:

— Юк, калмый, туташ, кәкре юлга кергәнда һаман шундый үзеңне-үзең җумалаулар була. Менә без дә рус гаскәренә кергәнда бу көнне уйлаганмыни? Үзеңнең татар солдатыңны өйрәтәсең, аңарга шул авыр юлда башчылык итәсең, аңарга руслар арасында ярдәмче буласың, диелгән, югыйсә кем тугрыдан-тугры үзенең халкына каршы шул юлга керә ала?... Кем кардәшенең башын чаба торган урыс балтасының сабы булырга разый була?.. Менә бу көн килде. Мин, Айа Суфияның башына төрекләр төшерган тәрене татар өчен, үзем кебек төрек-татар гаскәре берлә бердәнбер төрек илеи саклый торган туганнарым төрекләргә каршы сугышырга, аларны үтерергә, артымнан кила торган теге урыс тәресенә юл ачарга кирәк?.. Мена мин бер төрек угылы төрек, алты йөз еллык төрек-рус өчен җанын фида итә торган төрекләрнең иң нечкә йирен, иң зәгыйфь ноктасын табып, рус кылычы берла шул тарихи тартышны кисәргә тиеш! Ник? — Аның күзенә яшь тыгылды. Тавышы бозылды.— Чөнки мин Мирхәйдәр Тимергали генә түгел. Чөнки мин рус урдусының полковнигы Мирхәйдар Тимергалиев!»

Аның күзеннән яше мөлдерәп акты. Ул берни әйтергә белмәенчә утырды. Бөтен тирә-юнь аптырап, катып калды. Тимергали балаларча иттереп елавында булды. Һәр кеше шелтәле күзләрен Фәридәгә текте. Тавышсыз-тынсыз көенчә полковникның елавын, Коръән тыңлаган кебек, ихлас берлә, тирән бер әһәмият берлә тыңлады. Бераздан Әсмабикә

акрын гына чыгып бер чынаяк су китерде. Тимергали бердән шуны эчеп җибәрде, үзен-үзе бераз туплады, аякка калыкты. Көчләнеп көлгән тавыш берлә: «Картлык баса, сеңерләр тыңламый башлаган», — диде дә күрешә башлады. Фәридә үзенең гаебен эретер өчен кебек:

— Без әле, полковник, сезгә музыка уйнармыз дип тора идек, китәссз дә мени? Әле бит бик иртә, утырыңыз. Зәйнәп әнә яңы көйләр дә табып кайткан иде.

Шуньң артыннан бар да:

—Утырыңыз, утырыңыз, — дип кыстарга керештеләр. Болай чыгып китәсе килмәгәнгә, Тимергали да калды. Тагы элгәреге кебек пианино чалынды. Зайнәп йырлады. Лакин бу юлы Фәриданең пианиносы тагы моңрак уйнады, тагы нечкәрәк ыңгырады. Зайнәпнең тавышында еглау, сыкрану аһәңе тагы куерак сизелде. Кичнең яртысы уткәч кенә Тимергали өйгә таба кузгалды.

Арыслан гаиләсе генщ бик озак бер-берсеннан аерыла алмады. Бик озак алар Тимергалине сцйләде. Һаммәсе үзенчә тәфсир итте, һәммасе аңарга каршы тагы бер тирән хөрмәт биләде. Ләкин Фәридәдә үзе аңламаган бер хис уянды. Уд шуның мәгьнәсен белә алмаенча таңга кадәр йоклый алмады. Ул шул карт полковникта үзе уйлаган бер төрек каһарманын тапты. Ул аны сөйде, үзена-үзе икърар итә алмаса да, ул аны сөйде. Иртәгесен уянып киткәч тә Фәриданең башына килгән фикер тагы шул ук — төрек жәбһәсенә һәмширә булып китү будды. Ул анда ни булачагыны белмәсә дә, рус сугышы хакындагы һәмширәларнең тормышының бик татсыз, тәмсез иканен белсә дә, аны әллә нәрсә өстерәде, аңлашмаган бер көч аны шунда таба этте, төртте. Аңарга төрек дөньясынын зур бер мәсьәләсе шунда хәл ителә кебек булды. Төрек дөньясынын яшәү-яшәмәү эше шунда каралачак кебек тоелды. Төрек дөньясының әле русларга, әле кытайларга, әле гарәпләргә, әле фарсыларга өмәче булып йөрүе, яисә үз башына үзе тора башлап, үз байрагына хезмәт итә башлавы шуннан башланачак кебек булды. Шундагы кырык төрле төрек кабиләләреннән җыйналган төрек гаскәре шунын оеткысы була, шул рус мундиры астында зур төрек рухын саклый торган полковник Мирхәйдәр Тимергали шуның бер байраклары була кебек хис ителде. Үзенең бер төрек кызының милли вазыйфасы, нинди каршы көчләр килмәсә дә, шунда булу дип башына әллә нинди куәт тукыды, беркетте. Ул шул фикер артыннан куышты, ләкин гаиләсенең тәмам каршы килуе һәм дә үзенең моңганча барган тирә-юненең, бөтен төрекче агымнарының буның бу эшенә рус өмәчелеге дип кенә каравы аны борчыды, аны чыга алмас урманга сукты. Ул алай уйлады, болай уйлады, һичбер төрле чыгыш таба алмады. Полковникка барып ялынырга, ялварырга булды. Тәрбиясе аңарга ирек бирмәде. Атасы-анасына сүз тыңлатырга булды. Егерме, егерме биш ел бербуйдан бу гаиләнең русларга каршы дошманча эшләнгән фикеренә барып бәреләчәген хис иттс. Дуст-иш җыеп бер жәрәян ачып, «жөбһәгә» дигән бер шигар ашасыннан утмәкче булды. Бөтен төрек мөнәүвәренең сугышка бойкотларына каршы бер эш эшли алмаячагын, киң бу агымга каршы йөзә алмаячагын сизенде. Ләкин барасы килү — манигь күбәйгән саен артты. Башы зур бер үзсүзлелек берлә шуның юлларын эзләвендә дәвам итте.

Менә ишектә кыңгырау кагылды. Кем бар икән, кем килә икән дигән кебек колагын салды. Өйдән беркем дә ишеккә таба бармады, ишек ачылмады. Ул: «Ни булды, әни кайда? Хезмәтче кыз кайда?» — дигән фикерне хәл итә алмады, икенче мәртәбә тагы куәтлерәк ишек шылтыратылды. Ул: «Беркем юк, куресең», — дип, кызу-кызу киенгәләп, ишеккә барып өлгермәде, тагы өченче мәртәбә бик озын кынгырау шылтыратылды. Ишек ярыгыннан ул телеграм ташучыны күрде. Ачар-ачмас: «Телеграмма, мөстәгъҗәл, кул куеңыз! — дип ишеккә бер кәгазь төртелде. Фәридә карамаенча гына кул куйды, карамаенча гына телеграммы ачты: «Җомга көнсез юлга чыга алмыйм, вакытың булса, көт. Исән, бик сөендем, убәм. Кызың Сөем». Фәридә бер укыды, аңламады, ике укыды, анламады. Адресын карады, узләренә чыкты, тагы укыды. Мәгънәсеннән полковникка икәнен аңлады. Кеше телеграмын ачып укуы өчен полковник алдында тагы бер гөнаһ эшләде кебек хис итте. Тагы кызарды, тагы буртенде. «Әти! Әни!» дип әтисен эзләде, әнисен карады. Бар да торле эш берлә чыгып киткәнгә, өйдә беркемне дә таба алмады. Шул телеграмны хәзер үк белгертү, хәзер үк полковникка әйтү вазыйфасы дип уйлап, телефонга чапты. Телефон

китабыннан колагының очына гына кереп калган отельнең номерын эзләде. Телефон сукты, мәшгуль булып чыкты. Бераздан тагы какты, әллә нинди бер бюро берлә телефон тоташты. Фәридә аны көчкә өзде. Өченче мәртәбәсендә отель конторын тапты, ләкин аның соравына каршы телефонга әллә нинди бер әрмән килеп, төрле тәмсез сүзләр сөйләргә кереште. Фәридә кызды, ачуланды, телефонны өзде. Тагы шылтыратты, менә тагы контор бирелде, аннан: «Полковник Тимергалиев хәзер гена вокзалга китте», — дип җавап алды.

Фәридә озак уйламады, кызу-кызу киенде дә вокзалга чапты. Барып җитә алмау куркусы берлә мәшгуль булганга, болай бару ярармы, ярамасмы дигән фикерләр аның башына да килмәде. Вокзалга барып җиткәч кенә ул икеләнеп китте. Бу ничек булыр, моны ул ни дип аңлар, дигән бер шөбһә уятты, ләкин ул шөбһә дә «китеп бармасын» дигән уй берлә бик тиз онытылды. Фәридә башы, күзе берлә меңләп кеше арасыннан Мирхәйдәрне ә эзәләргә тотынды, анда чапты, монда чапты, буфетка керде, платформага чыкты, таба алмады. Вагоннарга кереп эзләмәкче булды, ишеккә тыгылган халыктан утә алмады.

Менә ул бер тәрәзәдән полковникның башын күреп калды. Баш югалса да, ул шунда барып, тәрәзәне шылтыратты. Элгәре бер сәудәгәр торып карады, Фәридәне танымады булырга кирәк, китте, аннан соң бер яшь эфисәр карады, ул көлгән йөз берлә Фәридәгә әллә нәрсә әйтте, мыегын сыпырды. Фәридә кычкырыбрак: «Полковник Тимергалиев!» — дип чакырды. Әллә бик каты кычкырдымы, әллә иттифакый гынамы, бердән тәрәзәдә полковник күренде. Фәридәне күрү берлә: «Бу ни булды, әллә чын да бу кыз китәргә дип килдеме?» — дип, унайсызланып кына каршы чыкты. Фәридә күрешер-күрешмәс:

— Менә сезгә телеграм, өйдә беркем дә юк иде, мин әтигәдер дип белеп ачтым, гафу итеңез! — диде. Тимергали телеграмга сөенеп китеп:

— Рәхмәт, рәхмәт, бик зур рәхмәт, мәшәкатьләнгәнсез! — дип Фәридәнең кулын кысты. Фәридә:

— Алай булса, ачуланмадыңыз, мин куркып килгән идем, әле кичә дә мин сезне унайсызлаттым, гафу итеңез! — диде. Тимергали, кызыннан алган телеграмга сөенеп киткәнгә:

— Ул ни дигән сүз, рәхмәт, рәхмәт, менә кызым киләчәк, инде мин көтә алмам. Беләсез, үзен озата күреңез. Аннан, туташ, мин инде аны ике ел күргәнем юк, кем булгандыр, белмим, институтта укыды, сез аңарга милли яктан тәэсир итәргә тырышыңыз. Яшь кеше бит, белеп булмый нинди агым артыннан ага торгандыр... Үзем рус өмәсенә бик күп йөредем. Кызым алай булмасын иде... Угылым да шул өмәгә әрәм китте... Менә үзеңез тесле булсын иде, — диде... Фәридә:

— Алай булгач, ник соң сез минем фронтка баруымны телемисез?— диде. Полковник аптырады:

— Теләмим түгел, анда сезгә урын түгел, дим, сез анда юкка әрәм булу ихтималыңыз бик якын. Уйнаган бер ядрә, көтелмәгәндәге бер сөңге сугышы... Тагы, беләсез, гаскәр сугышта бик бозылган... Ниләр-ниләр булу ихтималы бар... Шуның өчен генә, башка бер сәбәп юк.

Фәридә:

— Юк, полковник, минем күңелем шунда омтыла, шунда әллә нәрсә табар кебек була... Шунда бару миңа тиеш икәнен, куңелемнең әллә кайбер йире тоя. Бөтен барлыгым шунда барырга җан ата... Әллә нинди бер тавыш: «Фәридә, бар! Бар!»— дип тора. Мин, полковник, бүген төн буе шуны уйладым, йоклый алмадым, һич юлын таба алмадым. Рөхсәт биреңез, полковник, барыйм инде! — диде дә полковникнын кулын тотты.

Үзеннән башка кем дә белми торган башындагы планны, үзенең фронтта эшләргә дип кистереп куйган карарыны, шул яшь кызның, монда гына очраткан яшь кызның күңеленең әллә нинди бер кырые берлә сизенгәнен белде вә шул төреклек эшендә үзенең төрек рухы берлә катышырга омтылуын күрде... Ул эченнән:

«Димәк, минем фикерем кешелернең күңелләренә ут сала торган, йөрәкләренә дәрт сала торган бер милли эш. Димәк, минем бу эшем тугры бер эш?» Фәридәнең җан күңелдән

барырга теләвенә дә эченнән сөенде, кәефләнде. Фәридә шуны күргән кебек тагы бер мәртәбә:

— Барыйм инде соң! — диде. Полковник:

— Алай булса, менә ничек, әгәр этиеңез, әниеңез риза булса вә шуннан башка бер адым атламаска сүз бирсәңез?..

Фариде:

— Бирам, бирам!»— диде.

Полковник:

— Тагы бер шарты бар: сезгә авырлык булачагын сизгәч тә кайгарып җибәрергә булсам, каршы килмәсәңез?

Фарида:

— Юк, килмәм!— диде.

Тимергали түрән китүгә күпме вакыт барлыгын сорашты да, буфетка кереп, Арыслан Улмәс угылына, Әсма ханымга, Фәридәне Сөем берлә җибәрсәләр, бөтен масьулиятне үз өстенә алачагын, үз баласы кебек мөгамәлә итәчәген, кайвакыт чакырсалар, шунда кайтарачагын бәян итте. Штабтагы бер түрәгә Фәридәгә кәгазьләр хәзерлау хакында үтенечле бер кәгазь дә язды. Ике хатны да берга салып, пакетны мөһерләп, Арыслан Улмәс угылына тапшырырга дип, Фәридәгә тоттырды:

— Сөем килгәч тә миңа телеграм бирсен, чыгуыңыздан мине хәбәрдар итеңез. Ничек тә монда Сөемнең озак калмавы тиеш иде, — диде... Актык кыңгырау кагылды. Полковник зур уйларны уйлап җәбһәгә таба, Фәридә дә шул ук уй берлә өена таба юнәлде. Ләкин икесенең дә уйлары төрле булса да, хыяллары бер иде, омтылган гаяләре бер иде... Төреклек иде...

* * *

Сугыш йиренә килеп житү берлә Тимергали үзенең башында эшләнеп беткән планын эшкә чыгарырга кереште. Аның, хисабы буенча гомуми һөҗүмгә кадәр әле ике атна, егерме көн кадар вакыт бар иде. Шул кыска мөддәттә ул бөтен хәзерлекләрне күреп бетәргә тиеш һәм да бик сак көенчә эшләп, үз алаеның, рус забитларын, күршесендәге әрмән, рус алайларын һич шөбһәгә төшермәенчә, бөтен гаскарне, коралны, хәзинәне кулындагы гизле планнары берлә төрек тарафына күчерергә тиеш иде вә төрек гаскәрен шул зур һалакәттән коткарып алырга тиеш иде. Аның берничә атнадан бирле башында кайнаган вә пешкән фикере шул иде. Шуның өчен ул гаскәри киңәштә бөтен фронтның мәгьлүмәтен туплаган иде, шуның өчен, ул үзенең, бердәнбер кызын монда калдырмас өчен, Сөемне чакырткан, шуның өчен һәр минутта алга барырга хәзер иттереп гаскәрне өлгерткән иде.

Ләкин аның бу планын унайсызлаткан икенче бер нәрсә дә килеп чыкты. Аның берсе — төрек ятимнәрен жыярга килгән комитә әгъзалары, икенчесе — Фәридәнең килуе. Ул үзенең эше бетеп, мәсьәлә ачылгач, бу комитә әгъзаларыны, бергә булганнар дип, шөбһәгә алынуларыннан, бөтен Кавказ мөселманнары арасында каты бер террор башланудан курка иде. Икенчесендә, Арысланнар гаилесенә бик зур шөбһә төшереп, шул матур төрек гаиләсенең һәлак булуыннан шикләнә иде. Шуның өчен ул бу мәсьаләләр хакында бик катгый карар бирергә булган вә мөмкин кадәр тиз үзенең бу комитә берлә дә, Фәридә берлә дә мөнәсәбәтен кисәргә тиеш тапкан иде. Аннан соң үзенең рус забитларына каршы хәрәкәте берлә йирле забитларга каршы тотачак юлын билгеләү кала иде. Дөрестән әйткәндә, ул боларның һәммәсен дә хәл дә иткән иде: актык чиккә кадәр беркемгә бер хәбәр белдермәскә, штабтан алынган әмер иттереп бөтен алайны, төнге бер маневр берлә, төрек тарафына күчерергә! Шуны табигый юлдан алып барыр өчен ул кайткан көнне үк үзенен бөтен рус вә төрек әфисәрләрен туплады. Ишеккә каравыл куеп, сугыш иптәшләреннән һичкемгә сүз чыгармаска сүз алып, аларга тиз көннән һөҗүм өчен әмер киләчәген, боларның жыентык алайларына төрек фронтыны яру вазыйфасы йөкләтелгәнен, шуңарга һәр минутта хәзер булып торуның кирәклеген вә буны, солдатлардан бигрәк тә, шундагы калган төрек

бала-чагасы, хатын-кызыннан саклау тиешлеген аңлатты. Русларның һичбер төрле шөбһәлерен уятмас өчен, Истанбулга бармаенча мәсьәләнең хәл ителмәячәген сөйләде вә шул планның бер кисәге иттереп: «Штаб башы бундагы ятим балалар, хатын-кызларны мөмкин кадәр тиз артка күчерергә әмер итте. Шул эш берлә мәшгуль булыр өчен Кавказ мөселман комитәсенә рөхсәт бирелде. Барыңыз да шул эшне тиз бетерер өчен комитә әгъзаларына ярдам итеңез, фронт тизрәк пакьланылсын!»— диде. Барысы да полковникның фикерен кабул итте. Шунда ук тиз көндә шул ятимнәр эшен бетерер өчен бер рус эфисәренә киң сәләхият тә бирелде. Йкенче көнне ул күршедә тора торган куңелле әрмән алайларының башына һәм дә сул канаттагы казачий полкының командирларына хосусый хат язып үзенә килергә чакырды. Ахырында, шактый аркадашча сөйләнәчәк әһәмиятле сүзләр бар, дип, сүзне кисте.

Шул көнне үк ул Казан татары мөгаллименнән булган Ибраһим дигән бер эфисәрне чакырып: «Сез русча да, татарча да яхшы беләсез, менә штабтан бер гәзитә бирделер, шуны тиз генә тәрҗемә итеп биреңез. Әгәр аңлашылмаган йире булса, миңа килеңез, ләкин эшне бик ачык йөртмәңез», — диде... Кызына, Фәридәгә урын хәзерләргә бер забитка әмер бирде. Кулындагы гизле мәгълүматны юлга куеп язарга утырды. Ул эшкә керешеп өлгермәде, хезмәтче солдат: «Әфисәр Ибраһим килде», —диде. Тимергали гизле кәгазьләрен, туздырган яшерен хариталарын алып куйды. Төсенә командир кыяфетен бирде, кертергә кушты.

Ап-ак булган Ибраһим кереп басты. Полковникка аның аяклары калтырый кебек булды. Ул дерелдәгән тавыш берлә:

— Полковник, мин бу хезмәтне эшли алмыйм, мине азат итеңез, — диде, үзе күзен түбәнгә төшерде. Мирхәйдәр белмәгәнгә салынып: — Ник, ник? Сезнең бит телеңез җитәрлек! — диде.

Ибраһим хәл алды:

— Полковник, бу мәкалә бит безгә, бөтен төрек-татар гаскәренә каршы язылган бәяннәмә, моны бит штабка бирелсә, моны язучы бөтенләй һәлак булачак... Мин бу эшне эшли алмыйм, мине, полковник, азат итеңез!— диде.

Мирхәйдәр көлде:

— Мәкаләне укыдыңызмы?

Ибраһим:

— Укыдым, бер түгел, өч укыдым. Шуңарга сезгә килдем. Мине азат итеңез!

Мирхәйдәр көлгән рәвештә:

— Бердәнбер исән калган төрек илен ватарга барырга, берденбер исән төрек дәүләтен бетерергә, Айа Суфияга тәре тагарга барырга синең көчең житә дә, әллә нинди бер язучыны хәрби мәхкәмәгә бирдерергә көчең җитми? Бу ни дигән сүз? Монда нәрсәдер мин аңламаган бер сер бар! —диде. Ибраһим кызарды, бүртенде, калтырана башлады. Башыннан әллә нәрсә җавап эзләде:

— Гаскәри хезмәт бит, ант бар бит, антны боза алмыйм, шуңарга барам! — диде. Мирхәйдәр тагы көлде:

— Русиянең зураюы, киңәюе, баюы өчей бөтен дөньядагы төрек халкының, хәтта бөтен мөселман дөньясынын бердәнбер арка таяначагы булган Төркияне бетерергә тиеш табылса, син шул антың буенча шул эшне эшли аласын? Шулай бит? — Ибраһим башын иде. — Шулай булгач, менә бу мөхәррир сине, мине, барымызны — рус өмәчеләре, халкымызны кисәр өчен ясалган рус кулындагы балтаның саплары, дип атый, димәк, безгә каршы килә, безгаә дошманлык эшли. Син шул антың буенча аны да хәрби мәхкамәгә жибәртергә тиеш! Бу мәкаләне бит безнең гаскәр укыса, без Айа Суфияге тәре тагарга бармыймыз, дию ихтималы бар. Безгә Айа Суфияге тәре тагарга кирәк, чөнки штабның әмере шул. Мин полковник булсам, син эфисер!— диде. Узе Ибраһимның күзенә карады. Ибраһим калтырады, дерелдәде, күзеннән мөлдерәп яшь китте, русчалап:

— Булдыра алмыйм, полковник! Хөкемгә бирегез! — диде... Мирхәйдәр урыныннан торды, Ибраһимның янына килде, жилкәсенә кулын куйды, күзенә карады. Ачык иттереп:

— Димәк, синең әле милли вожданың сәламәт... Димәк, әле урыс өмәчелеге канына сеңмәгән, син әле Шәехгали булырга омтылмыйсың? Шулай булгач, мин хәзер менә, полковник булмаенча, синең кебек бер төрек угылы, төрек әфисәре һәм дә соңгы мөстәкыйль Төркияне бетерергә өстләренә йөкләтелгән төрек әфисәре булып, синең сүнмәгән вөжданыңы бер сөаль бирәм: син, мин, башкалар шул юлда эшлергә кирәкме? Шул ант буенча барып, төрек милләтенең калганын да рус итеге астына таптарга кирәкме? Әллә, бу язучы әйткәнчә, рус өмәчелегеннән чыгарга кирәкме?

Ибраһим аптырады, җавап таба алмады, бераздан соң:

— Белмим, полковник, минем вөжданым шулкадәр газаплана, бер сүз әйтә алмыйм. Минем атам мулла иде. Бездә төрекләргә мәхәббәт шулкадәр зур иде, халкымызда төрекләргә каршы иман шулкадәр тирән иде, бөтен кортылышны Төркиядән көтә иде. Мин хәзер үземне шул төрекне бетеручеләр арасында күреп шашам. Ни эшләргә белмим. Бездә көч юк. Бездә тәшкилат юк!

Мирхәйдәр:

— Әрмәннәр ни эшлиләр? Әрзерумның, Трабзонның рус гаскәренә юлын ачкан кешеләр кемнәр иде? Әрмәннәр тугел идеме? Ник шундый эшне руска каршы азербайҗанлы, дагыстанлы, комык, төркстанлы, идел-уралլы эшли алмый? Ник шуны син, мин эшли алмыймыз?

Ибраһим:

— Соң, бит, полковник, тугрысын сөйлим: мин үзем качарга уйладым. Ләкин тегендә бит илемез бар. Мин качсам, башкасы качса, калган илемезгә бит русалар кылмаган начарлыкны калдырмаслар. Калганнар бит безгә ләгънәт укыр...

Мирхәйдәр:

— Әрмәннәрнең калганы юкмы? Аларга Төркиядә җәннәттерме? Ник алар эшлиләр?.. Юк, чибәр егет, синең әле милли вөжданың актив түгел, пассив кына, әрмәннеке актив!.. Ярый, бар! Әле синең башында бу фикерләр пешеп бетмәгән, ләкин беркемгә дә монда сөйләнгәннәрне сөйләмә! Руслардан, әрмәннәрдән шөбһә уяттырма, кирәк булса, чакыртырмын... Миңа хәзер полк мулласын җибәр! — диде. Ибрахим ктты, чыга алмады:

— Полковник, мин вөждан газабы берлә йоклый алмыйм, саташам. Күз алдыма төрек улекләре килә. Буалар, утермәкче булалар... Мин бу газапны күтәрә алмыйм. Миңа юл курсәт!

Мирхәйдәр:

— Синең кебек газапланган тагы төрек-мөселман әфисере бармы?

Ибраһим:

— Бар. Әнә теге комык Арыслан, төрекмән Какаҗан, теге дагыстанлы капитан, хаҗи угылы, бик күп унтерлар, бик күп гаскәриләр — һәммәсе эченнән яна-көя!

Мирхәйдәр идәндә әйләнде, Ибраһимныә алдына килеп басты:

— Менә моннан чык та, узен ышанган әфисәр, унтер әфисәр кебек гаскәрнең аңлыракларын жый да, беркемгә дә белгертмәенчә, шул мәкаләне укы. Шундагы сүзләргә фикерне эшләт, ләкин гәзитәне миннән алганыңны сөйләмә! Аннан фикернең ничек баруын миңа белдерерсең! —диде.

Ибраһимнан соң полковник гизле гаскәри серләрне юлга куйды. Рус гаскәренең хәзерге торган йиренең планын икенче бер кәгазьгә төшерергә тотынды. Киләчәк һөҗүмнең максатларын, юлларын эшләргә кереште. Озак эшләп арып беткәч кенә, төннең бик соң икәнен күреп, ятарга хәзерләнде. Гадәте буенча урамга чыкты. Үзенең алаеның тора торган йирләрен үтте. Менә бер төрек өендә яна торган утка күзе төште. Ул акрын гына шунда таба китте. Кечкенә тәрәзәнең каршысына барып басты. Бүлмәдәге кешеләрне карарга тотынды. Анда унлап, унбишләп кеше жыелганнар, әллә нәрсә хакында сөйлиләр, кычкырышалар иде. Якынрак килде. Ибраһимның, тагы бернича әфисәрнең, хәрби мулламын, берничә

унтер әфисәрнең йөзләрен таныды. Тагы килә төште. Бәгъзе сүзләрен дә ишеткәләде. Һәммәсенең йөзләре кызарган, күзләре ялтыраган, бар да бик каты гасабиләшкән иде. Сүзләр баягы гәзәтә мәкаләсе өстендә бара иде. Ул озак кына тыңлады, әллә керергәме икән дигән фикергә дә килде. Ул фикердән дә кайтты. Зур бер адымны атлаганын хис итеп, тынычланып өенә таба борылды.

* * *

Икенче көнне гади көннәр төсле кебек иттереп, полковник Тимергәли иртә үк эшкә керешге: гаскәрне күздән кичерде, атларга күз ташлады, кәнсәләриягә керде, хастаханәгә кереп докторлар берлә сөйләште, яңы ике һәмширә килүен белгертте, хасталарның хәлләрен белеште. Килгән кәгазьләргә җаваплар язды. Көндәлек эшләрен эшләде, әшләтте. Очраган әфисерләр берлә элекке кебек аркадашча, каты куллы командирча мөгамәләдә булышты. Эш берлә очраган Ибраһимга да, гуя бернәрсә булмаган кебек итеп, искечә командирлыкта булынды. Килгән комитә әгъзаларына ярдәмне бик кызу тотса да, аларга каршы рәсмилекне ташламады, эшләрне мөмкин кадәр рус әфисәрләре ашасыннан әшләтергә тырышты. Өенә китәргә булганда гына Ибраһимга бүген аштан соң сәгать өчтә үзенә гәзитә хакындагы фикерләрне китерергә, дүрттә хәрби муллага килергә әмер итте. Биштә комитә кешелере берлә сөйләшергә вакыт билгеләде. Үзе, көтелмәгәндә әмер килеп чыкмасын дип, ишеген бикләде, рус көченең, Кавказ җөбһасенең харитасын ясарга тотынды. Ул аны элгәре кечкенә кулда әркяне хареб забитлары өчен генә эшләргә башласа да, бик күп вак, ләкин әһәмиятле мәгълүматны сыйдыра алмаганга, зур масштабка күчте. Хаританыд кемнең кулына төшәсене белмәгәнгә, гади төрек афисәрс аңларлык дәрәҗәдә эшләргә тотынды.

Фронт бик киң булганга, һөҗүм планы бик зур булганга, моны харитага төшереп бетерер өчен әллә никадәр вакыт кирәк булды. Мәгълүмат бик төрле-төрле булганга, боларны гади афисаргә аңлатырлык ясау өчен бик күп баш ватарга тиеш булды. Полковник үзенең егерме сигез еллык рус гаскәрендәге бөтен туплаган мәгълүматын бирү, хәзерге төрек-рус тартышында үзенең бурычы, үзенең милли бурычы дип иман иткәнгә вә моңганчыга кадәр рус өмәсендә йөруен, рус балтасына аңламаенча сап булуын төреклек алдында шундый бер хезмәт берлә генә юарга мөмкин дип ышанганга, бөтен тәҗрибәсен, бөтен үзсүзлелеген җыеп эшендә дәвам итте. Күптан сәгать өч булса да, күптән Ибраһим көтә торган булса да, фронтның бер почмагының харитасын, истыйляхи рәсемнәрен ясап бетермәс борын ишекне ачмады, аны кертмәде. Хезмәтче солдатына чәй ясарга кушып, Ибраһимны чакырды вә солдатны гаскәри муллага бер ярты сәгать соң килсен дип әйтергә җибәрде. Өйдә үзләре генә калгач, чәй янына Ибраһимны утыртып сөйләтергә тоынды. Ибраһимның сөйләгәне көтелгәннән да зур булып чыкты.

— Гаскар башлыкларының гөрек кыйсьменец зур бер өлеше бик авыр вөждан газабы астында. Алар һәммәсе да бу эштән чыгыш эзлиләр. Сезнең штабтан килеп ясаган мәгърузәңез боларның бөтен сабырларын төркәндергән. Кайберләре: һөҗүм башлангач та төрекларгә күчәргә кирәк, диләр. Кайсылары: хазер үк берәм-берәм качу юлында булырга кирак, диләр. Гаскәр арасында да зур бер эчпошу бар. Алар арасында хатлар язып, ярдамнәр итеп, үзенә-үзе гаскарне караткан бер Казан мөгаллиме бар. Исеме Вахит Фахретдин. Шул да әллә нинди бер план кора булырга кирак. Менә хәл шул.

Полковник:

— Арада штабка сүз йөрта торгам яиса мондагы рус әфисәрләренә хебәр бирә торганнар бар диме?

Ибраһим:

— Бар булырга кирәк. Күптән түгел генә килгән башкорт прапорщигы һәмширә Королева берлә бик якын, диләр. Королева Петербургтагы әллә нинди ярлы аристократ фамилиясенең кызы. Үзе чи урыс. Гаскәриләрдән бер-ике рус әфисәрләрендә денщик булып тора торган яшьләр бар икән. Алар, тегеләй генә, авызында сүз тота алмаса гына!

Полковник:

— Мина ничек карыйлар?

Ибраһим:

— Сезгә эфисәрләрдән ышаныч зур. Ләкин кубесе сездән бу һөҗум планын өстенә алмас, алай итеп, болай итеп безнең гаскәрне читтәге фронтка күчертергә тырышыр, дип көткәннәр икән. Хәзерге хәбәр аларны бик аптыраткан.

Полковник:

— Һаман шул пассивлык...

Ибраһим:

— Ни эшләсен, юл юк бит, полковник! Гаскәрләр арасында шактый дошманлык бар. Андый-мондый эшеә кадәр дә мөмкиндер.

Полковник уйланды:

— Капитан Фәхрелисламов ни фикердә?

Ибраһим аның анда булуын полковникның белүеннән аптырап китте. Моның мәгълүмәт ала торган башка кешесе дә бар, күрасең, дип шөбһәләнеп куйды. Элгәре капитанның полковникка каршы булуыны сөйләмәскә карар биргән булса да, ап-ачык сөйләде. Ахырдан:

— Ул бит бик динле кеше, мене монда, фронтта рузасын калдырмады, намазын укыды. — Мин төреккә каршы сугышып мордар китәр хәлем юк, — ди.

Полковник Ибраһимга яңы әмерләр бирде, тагы башкалар берлә сөйләшеп аңлашырга кушты вә гаскәри мулланың да фикерен белешеп, Ибраһимны чыгарып җибәрде. Мулла берлә сөйләшергә планнарын хәзерләде.

Бу гаскәри мулла дигәне Тимергәлинең элгәреге заманда полкларда күргән иске унтер эфисәрләрдән булган муллага, полковник ни кушса: «Боерыкыңызга хәзермен!» — дип тора торган гаскәри муллаларга бер дә охшамый иде. Гади солдат булып хезмәт итмәс өчен гаскәрлектан качып кергән бу мулла иске-искедән мулла нәселеннән килгән. Әдәбият, гыйлем берлә шөгыльләнә торган, гаскәрләр арасында йырлар, экиятләр жыя торган, эфисәрләр берлә үзен-үзе эре тотып: «Мин дин башы» дигән бер урынны саклый торган, үткен генә, салмак кына, куркак кына бер яшь мулла һем дә кирәкле вакытында солдатларны, эфисәрләрне авызына каратырлык сүз сөйли белә торган бер мулла иде. Ул үзенең сугышка, гаскәрлеккә каравын бик яшерә. Һаман: «Без ант иткән, ант!» — дип читтән таярга ярата иде. Полковник үзен хөрмәт иткәнгә, Мирхәйдәргә каршы хөрмәт саклый, аны рус эфисәрләреннән һаман югары итеп күрсәтергә тырыша иде. Үзе бераз хәйләле, бераз сәүдә ярата торган, бераз гына кеше күрмәгәндә эчкәләп тә ала торган, бераз хатын-кыз берлә дә булыша торган яшь мулла иде. Полк исеменә Казаннан, Уфадан, Оренбургттан, Мәскәүдән, Бакчасарайдан, Бакудан гәзитәләр, китаплар алдыра. Үзенчә кечкенә генә бер полк китапханәсе ясарга маташа. Гаскәрләрнең дини-милли ихтыяҗлары өчен бертуктамаенча кәнсәләриягә мөрәҗәгатьләр ясый, полковникка кадәр килеп акчалар тәгайен иттерергә тырыша иде.

Менә шул эченнән мөселман, милләтче мулла берлә хәзер полковник Тимергали сөйләшергә, аңлашырга, аның зәгыйфь бер җиренме, йә иманлы бер ноктасынмы табып, шул җирен басарга тиеш, шуннан бер тавыш, мөселман-төрек тавышы ишетергә тиеш иде. Гадәттәге кебек полковник мулланы ишеккә кадәр барып каршы алды, гадәттәге кебек полковник аны каршысына утыртты, гадәттәге кебек «хәзрәт» дип сүз сөйләде. Мондагы гаскәрләрнең дини хәлләрен сорашты. Авырулар, үлгәннәрнең ихтыяҗларын белеште. Тифлистә күргән әдәбият кичәсен аңлатты. Кызының һәм дә аның берлә бергә тагы бер татар кызының һәмширә булып килүләрен хикәя итте. Гаскәри киңәш мәҗлесенә килеп җитеп, андагы эшләрнең китешен, әрмән сәүдәгәрләренең эшләрен, инглиз полковнигының, штаб башының сөйләгән нотыкларын сөйләде. Ахырдан: «Менә мин хәзер бер мөселман, бер төрек угылы — төрек, ләкин тарихның кушуы буенча менә монда рус ягында калган бер төрек эфисәре сездән бер сөаль сорыйм, вөҗданыңыз кушканча ачык җавап биреңез. Хәзер мине полковник дип уйламаңыз, бер рус солдаты дип кенә төшенеңез.

Менә минем динемнең баш иле, хәлифенең туган йирен бетерер өчен христианнар яңа әһле салиб сугышлары ачтылар. Максатлары — мөселман хәлифәтенең үзәге Төркияне бетерү, Истанбулны алу, Төркияне бүлү, аннан бер Әрмәнстан ясау, аннан тагы Русиянең яңы губерналарын күбәйтү. Менә син, бер татар милләтчесе, татарның үзе гене бит бер сәяси, мәдәни эш эшли ала дип ышанмыйсың, рус дингезе эчендә калган җиде-сигез миллионлы бер халык, үзеннән-үзе генә башка бер мәдәният, бер дәүләт мәйданга китерә ала дип ышанмыйсын? Син бит боларны һәммәсен төрек дөньясы берлә бәйләп, боларны һәммәсен тәсбихтвәге аерым-аерым төймәләр дип кенә уйлыйсың. Боларның баш төймәсе — бисмилласы Төркия дип ышанасың. — Мулла бер суз әйтмәде, полковник дәвам итте: — Һәм ул шулай да: болгарлар, сербләр, чехлар — һәммәсе бит үзләренең милли истикълял тартышуларында урыс янына тупландылар. Аннан ярдәм алдылар... Менә хәзер тәсбихне дошманнар сүтеп җибәрер өчен аның бисмилласын югалтмакчы булалар, аны бәйләгән җебен өзеп-өзеп ыргытмакчы, астындагы төймәләрне аерым-аерым берәр төймә көенчә генә калдырмакчы булалар. Шул йипне кисүдә, бисмилланы бетереп ыргытудагы иң авыр йөкне безге йөклиләр. Менә без бүген-иртәгә каршымыздагы төрек гаскәрен кисеп, суеп, артымыздан килә торган рус көченә юл ачарга тиеш. Штабның әмере бу. Менә мин шуны, Мирхәйдәр Батыргәрәй угылы Тимергали, үземне-үзем төрек-татар дип уйлаган, үземне-үзем мөселман дип уйлаган Мирхәйдәр, шуны эшлимме? Дин ягыннан минем шул эшемә ничек дип каралачак? Милләтчелек ягыннан мин Шаехгалилек итимме?» — Полковник авыр сулап туктады.

Мулла аптырап калды, бер сүз дәшә алмады, аны курку басты. Ул хәйләгә сабышмакчы булды. Лекин Тимергалинең баткан күзләрен күреп, бу сүзләрнең эчтән кайнап чыкканын сизеп, ул юлыннан кайтты, эченнән көч эзләде. Әтиең, бабаларың, шундый вакытта туп-тугры иттереп: «Әйе, бу дингә, милләткә хыянәт!» — дип, ап-ачык әйтә ала торган әтиләрем, вә шуның аркасында милләтенә өч йөз илле ел руслашудан саклаган әтиләрен, бабаларын хәтерләде. Күзен күтәрде:

— Әйе, полковник, мин сезгә мөселман мулласы булып әйткән җавабым шул: бу эш шәригатьчә гафу ителмәслек зур бер гөнаһ, алгаязе биллаһ, көфер. Милләтчелак ягыннан, шөбһәсез, милли хыянәт. Илемезгә, көнемезгә, тарихымызга каршы хыянат, —диде. Үзе дә шул сүздән куркып, аптырап калды.

Полковник:

— Шулай булгач мин ни эшлим?

Мулла:

— Сез безнең гаскәрне мондый авыр эштән читтә калдырырга кирәк иде, анда киләчәктә тагы күз күрер иде, бәлки руслар җиңә алмаслар иде...

Полковник:

— Аны булдыра алмадым, булдырырга тырышмадым да, инде ни эшләргә кирәк, менә хәзер ни эшләргә кирәк?..

Мулла:

— Авыруга сабышыңыз!.. Истигъфа итеңез!..

Полковник көлде:

— Ә бу гаскәрләр ни эшләр? Болар полковник Ивановның, Петровның, Назарянның командасында төрек иленә барсын, шул тәсбихне сүтсенме? Мин шуның өчен боларны көн йокламый, төн йокламый хәзерләдемме? Башка юл курсәт, башканы!

Мулла аптырады. Полковник аякка калыкты, идән буе бераз әйләнде:

— Менә нәрсә, мулла, хәзер мин бераз мулла булыйм. Синең дә, минем дә, бундагы бетен төрек-татар эфисәрләренең вазыйфасы бөтен гаскәр берлә, бөтен корал берлә, бөтен хәзинә берлә, бөтен яшерен планнар берлә Төркиягә чыгу... Шулай итсәк кенә без Төркияне һәлакәттән, үземезне дә, халкымызны да мәсхәрәлектән, руслашудан, бетүдән саклый аламыз. Менә сезнең мөселманлыгыңыз, милләтчелегеңез тугры булса, без, хәзер чех эфисәрләре, солдатлары унар меңәрләп эшләп яткан кебек, без дә шуны эшләргә тиеш, — диде.

Мулла аптырады, йөдәде, ни әйтергә белмәде, аны курку басты, ул авызыннан әллә ни мыгырданды. Полковник көлеп:

— Мулла курыкты... Хәзер, мулла, уйный торган вакыт түгел. Йә без урыс балтасының сабы булып төрек башына бер йомырык индерәмез, яисә шул балтаны, милләтемезнең бердәнбер мөстәкыйль мәмләкәте Төркияне саклау өчен, руска каршы чәверәмез. Башка юл юк! —диде. Мулла да шул фикергә кушылды. Тимергали шул юлда хәрәкәт өчен лазем булган эшләрне аңлатты. Акрынлап шул фикерга гаскәрнең аңлысын хәзерләүнең кирәген сөйләде. Шул атна-ун көн эчендә бер дини бәйрәм ясап, гаскәрнең дини, милли хисен уятырлык эшлор эшләргә лаземлеген аңлатты. Мулла да берничә көн эчендә уйлап, бер бәйрәм тәртип итәргә булып вә һичкемгә бу мәсьәләне сөйләмәскә сүз биреп аерылды.

Комитә әгъзалары берлә кыска гына сөйләп, үзләренең мөмкин кадәр тиз китәргә тиешлекләрен һәм дә кубрәк рус әфисәрләре ашасыннанрак хезмәт итәргә кирәклеген, менә бүген күрше фронт башлыкларына үзләрен такъдим итәчәген, алар берлә тиздән мөгамәләгә керү тиешлеген аңлатты. Ахырдан:

— Сезнең хәтнреңез калмасын, безнең берлә сезнең каты бәйләнелгәнеңез русларга, эрмәннәргә мәгьлүм булса, сезгә каршы да, безгә каршы да интрига башланыр, сезнең эш тә, безнең эш тә зарар күрер, — диде.

Карт доктор бик тиз аңлады, яшьләр бераз кәефсезләнделәр. Полковник болар очраган бер урыс эфисәренә полковникны сүгеп йөрерләр дип, наразыйлыкларыннан сөенеп тә куйды. Чыккан вакытта докторны алып калып:

— Безнең хакта, хосусән, минем хакта руслар, әрмәннәргә никадәр начар сүз сөйлисеңез, гомум эшкә шул кадәр файда иткән булырсыз, — дип, үзләрен кичкә, әфисәр клубында, киләчәк кунаклар хөрмәтенә биреләчәк ашка чакырып аерылды.

* * *

Кичкә таба килеп җиткән күрше казачийлар фиркасенең һәм дә күңелле әрмәни алае команданнарын полковник Тимергалиев рәсми киемдә үзенең япон сугышында алган бөтен медальләрен тагып каршы алды. Кырымда атлы гаскәр егетлеге вакытында императрицадан бүләк итеп алган, алмаз куелып алтыннан эшләнгән кара кош сүрәтен һәм дә япон сугышындагы баһадирлык өчен французлардан җибәрелгән «Лижиюн дуаунур» галәмәтен дә күкрәгенә йирләштерде. Бохара әмиреннән бирелгән, асыл ташлар берлә эшләнелгән, тәрилкә кадәр зур алтын медален дә урынына такты. Кунакларны бик дустча иттереп, ләкин үзенең дәрәҗәсен белгән зур бер кеше кебек кабул итте. Кыска гына исәнлек-саулыктан соңда мәсьзләне аңлатырга кучте. Элек баш штабның һөҗүм планын аңлатты. Ахырдан шуның булеге иттереп моны — Мирхойдәр Тимергалиевне, узенең жыентык атас берлә, төрек фронтыны ярыр өчен билгеләнуен вә аңар киң бер сәләхият бирелүен, вә аның янындагы атлы казачий алайлары һәм дә җәяүле вә атлы эрмән күңеллеләренә кирәк булганда аңарга ярдәм вазыйфасы йөкләтеләчәген сөйләде. Үзенең менә шул ватани вазыйфаны эшләр өчен бүген-иртәгә штабтан әмер көтүен, гаскәренең һәр сәгатьтә алга таба хәрәкәткә хәзерлеген белдерде. Шуның өчен күрше гаскәрләрнең дә һәрбер төрле көтелмәгән әмергә хәзер булып торулары лазем икәнен аңлатты.

Аннан сон шуның ук дәвамы иттереп, алай-болай төрекләргә хәбәр чыгудан сакланыр өчен, фронт буе йөри торган төрек бала-чагасы, хатыны-кызының моннан озатылуы кирәклекне вә шуңарга штабның катгый карары булуын, шул эш өчен Кавказ мөселманнары комитасенә штаб тарафыннан сәләхият бирелуен игълан итте. Шул эшкә ярдәм итеп, тиздән фронтны шулардан пакьлауны ватани бер хезмәт кебек күрсәтте. Мөселманнар ятимнәр комитәсенә ярдәм итүләре лаземлекне белгертте. Табигый, боларның һәммәсен дә дустча гына сөйләсә дә, тәмаман бер гаскәри сер иканен әйтергә онытмады. Уз тарафыннан бу алайлар хакында кирекле мәгълүматны вакларына кадәр сорашты, белете. Озын-озын сөйләшелгәннең соңында полковник шул хосуста үзенә

штабтан килгән әмер тугрысында күршеләрен хәбәрдар итәчәген вә аларның да хәзер булып торачаклары хакында сүз беркетелде.

Полковникнын курыкканы бер кантлы казачий полковнигы Комаренко булмаенча, әрмән күнелле алае башы Бастырмазян булганга, ул аңарда шөбһә уяттырмаска бөтен көчен сарыф итте. Якыннан беренче очраша торган бу әрмәнга чын монархист, тулы русчылык хисен калдырырга тырышты. Сүз арасында үзенен япон сугышындагы баһадирлыкларын, башыннан үтмәгән булса да, Төркстандагы йирле халыкка каршы эшләгән катылыкларын хикея итте.

Мәҗлескә барып зыяфот башлангач та, ул өй хуҗасы сыйфаты берлә падишаһ хәзрәтләренең исәнлегенә, рус гаскәре, кылычынын муаффәкыятенә беренче бокалны күтәрде. Үзенең эчергә ярата торган бер кантлы бер чиркәе әфисәренә теге әрмәннәрне мөмкин кадәр күп эчертеп исертергә кушты. Ибраһимга аларнын бундагы нинди рус әфисәрләре, марҗалары берлә мөнәсәбәттәлекләрен шымларга кушты. Төннең ахырына кадәр биюләр, эчүләр берлә вакытны үткәртеп, тегеләрне һичбер вакыт буш калдырмаенча сыйлап-сыйлап таң алдында гына озаттырды. Үзе тагы бер зур адымны атлады кебек хис итеп, тагы жыйган мәгълүматләрне рәткә китереп өене юнәлде.

Иртә берлә торып-тормас ук капитан Фахрелисламов ишекне какты. Фәхрелисламның тәмамән рәсми киемнәрдә булуына гаҗәпкә калырга өлгермәде, ул полковникка рәсми сәламнәрдән соң үзенең гаризасын бирде, тәмамән гаскәрчә иттереп полковникның эмерен тыңларга хәзер торды. Гариза авыруы сәбәпле ике атналык рөхсәт биру хакында иде. Авырулыгы да докторның шаһәдәтнамәләре берлә беркетелгән вә монда калуы ярамавы бик каты иттереп тәэкид ителгән иде.

Тимергали озын иттереп Фәхрелисламны сөзде. Анын күзе эчендә әллә никадәр газаплану, моңардан әллә никадәр ераклану күрде. Ул, бердән эшне икенчегә борыр өчен, рәсмияттән чыгып, төрекчәләп сөйләргә тотынды. Фәхрелислам моның бөтен сөальләренә һаман русча җавап биреп килде. Ул шуның берлә гүя: «Синең берлә минем арамда күңел берлеге дә, тел берлеге дә юк. Безне бергә бәйләгән нәрсә менә шул рус хезмәте, шул рус теле генә», — дигәнне аңлаткан кебек булды. Мирхәйдәр эченнон хурланды, ләкин Фәхрелисламны бик күптән таныганга, аның бу соңгы патлавы, штабтан китергән хәбәрләре, хосусән, кичәге соңгы нотыклары өчен мөселман рухының ташуыннан чыккан икәнен күреп торганга, шешне бердән сытмакчы булды. Туп-тугры иттереп:

— Беләм мин сезне, сез авырмыйсыз да, нитмисез дә, ләкин сез төрекләргә каршы киләчәк һөҗүм вакытында монда булмас өчен китәргә телисез. Сезнең иманыңыз шуны тели. Ярый, китеңез, мин рөхсәт бирәм! — диде һәм кәгазьгә кулын куйды...

Фәхрелислам аптырап калды. Ул тагы русчалап сәлам биреп чыгып китмәкче булды, ләкин теле тамагына ябышты. Ул бер сүз әйтә алмаенча катып калды. Тимергали шуннан файдаланып:

— Соң менә сез, узеңезнең әфисәрлегеңездән, доктордан кәгазь ала алуыңыздан, минем берлә ун еллык синле-минле булудан файдаланып, шул дошманнар файдасы өчен ике кардәш сугышыннан качып кала аласыз, вөҗданыңызны шул зур гөнаһтан саклый аласыз. Сезнең астагы гаскәрләр — солдатларны кемгә ташлыйсыз? Алар арасында сезнең кебек ышанган мөселман, сезнең кебек төрек йөрәкле егетләр юк дип беләсезмени? Әллә алар кардәш төрекнең бердәнбер мөстәкыйль илен изсә дә ярый дип уйлыйсызмы?.. Бу бит, гаскәрчә әйткәндә, куркаклык кына. Бармагын атып сугыштан калган солдат тәнен саклар өчен шул хәйләгә сабыша. Сез, имеш, узеңезнең рухыңызны, иманыңызны саклар өчен кыйласыз!..

Фәхрелислам:

— Полковник! — дип бер җавап бирмәкче булды.

Тимергали тыңламаенча дәвам итте:

— Хәзергә бөтен төрек дөньясының барлыгы-юклыгы сугыш сафына куелган чакта, эченнән мөселман бер төрек әфисәренең вазыйфасы, дошманны күргән тәвә кошы кебек башын комга тыгу берлә бетә дип уйлыйсызмы? Сез китсәңез, сезнең урындагы

капитан Петров, Иванов сез өйрәткән, сез гаскәр иткән шул мецләп төрек-татар баласын мөстәкыйль төрек иленең соңгы каласыны җимерергә алып бармый дип уйлыйсызмы? Юк, капитан! Хәзер андый хатыннар хәйләсе берлә эштән үтеп булмый. Йә бөк, йә чөк!.. Йә төрек, йә рус! Урта юл юк, ул беткән, капитан!

Фәхрелислам аптырады, кызарды, бүртенде... Тимергали дәвам итте:

— Менә мин дә егерме сигез ел гаскәр хезмете иттем, милләтем аеры булса да, ватан бер дип хезмәт иттем. Хәзер менә күрдем: бөтен хезмәтләр руска гына икән, руслык өчен генә икән. Минем халкымны, минем милләтемне изәр, хур итәр, кол итәр өчен икән. Хәзер менә без актык төрек илен мәсхәрә итәр өчен корал ителәмез... Мин хәзер аңладым, бик күп уйлардан соң мин милли балигь булдым. Соң булса да булдым! Штабның гаскәри киңәш мәҗлесендә үземнең рус кулында уенчык икәнемне күрдем. Шуннан карар бирдем: мин шул төреккә каршы җыелган йомрыкны русның үз башына индерергә дип карар бирдем. Шуның өчен фронтны ерту вазыйфасын алдым, шуның өчен хәзерләнәм, вакыт килгәч, шуны эшлим. Син бу мәсьәләдә минем берлә бергә булмыйсың икән, бар! Мин синең вөҗданыңа ышанам. Минем генә түгел, бөтен шул сигез-тугыз меңле төрек-татар гаскәренең серен саклый алырсын дип ышанам. Хуш, капитан! — диде дә борылды...

Фәхрелислам бердән аякка тезләнде:

— Мирхәйдәр, Мирхәйдәр, юк, мин гаризамны кире алам, мин калам, мин белмәдем... Мин кичәге кичәдән соң йоклый алмадым, вөҗдан газабы биләде. Шуннан гына эшләдем. Ни кушсан, синең әмереңдә! — диде. Тимергали аны идәннән торгызып өлгермәде, Ибраһим пешенеп, бүртенеп килеп керде:

— Полковник, харап булдык, бүген төнлә 20 солдат, полк язучысы Вахит Фәхретдинов берлә, төрек ягына качканнар. Безнең чик каравылчыларыбыз аларны тотып алганнар. Хәзер алар барысы да кулда, безнең урман эчендәге кышладан хазер телефон берлә хәбәр иттеләр...— диде. Тимергали дә, капитан Фәхрелислам да аптырап калды. Тимергали үзенең фикерен дәвам иттергән кебек:

— Боларның иманнары капитан Фәхрелисламовныкыннан ныграк икән шул, — диде. — Бу мәсьәләне ничек булса да читкә чыгармаска кирәк, безнең гаскәр эчендә шундый агым барлыгы штабка белендеме — хәзер безне моннан алалар. Капитан Фәхрелислам, хәзер шунда бар, мәсьәлоне тавышсыз-тынсыз бетер, кирәге булса, мулланы да ал... Яшерен разведкага җибарелгән төсен бирерге тырыш... Үземезнен русларга да беленмәсен, беленсә инде, әрмәннәргә чыкмасын!..— диде.

Тимергали шешнең тулганын хис итте, тимернең кызган вакытында сугарга тиешлеген тагы уйлады, тагы планны кызуларга булды. Сөемнең килеп житмәве, хариталарныә хәзер булып өлгермәве, гаскәр эчендәге яшерен тәшкилатның эшләнеп бетмәве кулны-аякны бәйләде, аны тагы гади эшләр берлә мәшгуль булырга кушты. Теге качкыннарның әзен югалтыр өчен мәулед бәйрәме хакында магъруҙә берлә килгән мулланың мәгърузәсен тыңлады. Аны кабул итте. Байрәмгә мачетне рәтка китерергә кушты. Шуның вакытларын төзәтер өчен күнелле иттереп гаскәриләр алырга рөхсәт бирде. Кичкә габа Тифлистән Сөем берлә Фәридәнен чыгуыннан телеграм килгәне кебек, Фәхрелислам да эшне тәмам җайлап, тегеләрнең берсен да тотмаенча, бер ялгышлык булган төсендә мәсьәләне хәл итеп кайтты вә бөтен егерме бер гаскәр тагы урыннарына урынлашты. 21 качкынның яшерелүе аларны гаскәри мәхкәмәдән саклап калу итеп аңлатылганга, гаскәр арасында шул эшнең башында булган Тимергалинең базары бик күтәрелде. Соңгы көннәрдәге аңарга каршы төшкән ышаныч тагы кайтты. Гаскәр эченең әллә кайбер йире берлә үзенең полковнигының күрәләтә ут эченә алып кермәвена, куралэтә мөселманлыкка зарарлы эш эшләмәвенә иманы куәтләнде.

* * *

Сөем берлә Фәридә берничә көн соң килеп чыкты. Сөем, ватан каһарманнары гаскәрләргә ярдәм итү тиеш, дигән уй берлә, Фәридә, бу бәхетсез төрек балалары төрекләргә жиңеллек ясау фарыз, дигән фикер берлә килгәнгә, икесе дә бик күп эш эшләмәкче булдылар. Анда чаптылар, монда чаптылар, хастаханәдән кайтмадылар, авыру гаскәрнең яныннан китмәделәр. Гаскәрнең бөтен мохтаҗ якларына җитәр өчен кебек кышлаларга киттеләр, окопларга кадәр бардылар. Гаскәрләргә хатлар яздылар, китаплар укыдылар, төймәләр тактылар. Берничә көм эчендә моңганча алайда булмаган бер яңалык керттеләр, күтәрмә кубардылар. Элгәре гаскәр боларга көлеп кенә караса да, берсе полковник кызы, икенчесе иптәше булганга гына жәберләнеп хөрмәт иткән кебек күренсә дә, боларның армый-талмый чабуларын күрү боларга каршы яңа бер хис уятты, боларның икесен дә сөйдерде. Гаскәрләр үзләнделәр, алар берлә синле-минле сөйли башладылар, көлешә башладылар, шаярыша башладылар. Үзләрен командир берлә бәйли торган яңа бер юл табып, болар ашасыннан әллә никадәр эшләрен эшләтә башладылар. Хосусән, боларның музыка да уйнап гаскәрләрдән татарча, төрекмәмчә, азербайҗанча хорлар ясаулары бик кәефләренә килде. Полк тәмам җанланды. Теге киләчәк бәйрәмгә алар бер әдәби кичә дә ясарга хәзерләнде.

Ләкин болар барысы да Тимергалинең кәефен бозды һәм дә аның планын да чуалтты. Фәридәнең шулкадәр гаскәр эченә кереп китүе, гүя монда бөтен гомере буе торырга килгән, бер дә китмәскә йирләшкән кебек хис калдыра башлады. Полковник анарга читтән-читтән генә анлатырга тырышса да, ул бернәрсә дә аңламады, китәргә уйламады, һаман эшендә дәвам итте. Арыслан Үлмәс угылы никадәр: «Сезнен кызыңыз булган йирдә безнең кызымыз булудан бер дә курыкмыймыз, сезгә тәмам ышанамыз», — дип язган булса да, Фәридәне, бигрәк аларның гаиләсен шул эшнең соңыннан киләчәк бәлагә эләктермәс өчен, аны кире җибәрергә кистерде. Амың мондалыгы полковникның аягын-кулын тагы баглады. Ул бәйрәм үткәч мотлака җибәрергә карарны эшләде.

Менә бәйрәм җитте. Рус әфисәрләренең зур кыйсьме күрше алайларга барырга рөхсәт алып киттелор. Вак-төяк рус, калмык солдаты калса да, алар бәйрәм эшләрендә бергә эреп киткәнгә, аңарга әһәмият бирелмәде. Гаскәрләр төзәткән мәсҗеткә өйлә намазына тәмам тәһарәт алып, полковник үзе дә барды. Бөтен мөселман әфисәрләренә дә килергә кушты. Алты-җиде мең мөселман гаскәре берлә бергә намаз укыды. Алар берлә бергә сәҗдәгә китте, дога кылды. Алар берлә бергә мулланың озын вәгазен тыңлады. Махсус хәзерләгән ашны да алар берлә бергә ашады. Кич берлә әдәбият кичәлерендә булынды. Фәридә, Сөемнең уйнауларын, әллә ничә төрле гаскәр төркемнәренең йырлауларын, биюләрен карады. Бер гаскәр берлә Фәридәнең лезгингә биюен, Сөемнең бер әфисәр берлә кайтарма биюләрен — һәммәсен җентекләде. Шундагы гаскәренең милли рухы ачылуын, аның тәмам икенче кешегә әверелүен күреп гажәпкә калды. Бер вакытны: әллә хәзер менә әмер биреп, һәммәсен бергә җыеп, ачыктан-ачык төреккә чыгамыз дип әйтеп, күтәрелеп чыгаргамы дигән уйга да килде. Тагы эшлисе эшләр бетмәгәнгә, тагы туктап калды. Ләкин Фәридәнең гаскәр арасындагы хөрмәтене күреп бераз курыкты. Бу кыз, бу планнан хәбәрсез кыз, андый-мондый бернәрсә эшләмәсен дигән фикергә килде вә аны тагы бер мәртәбә җибәрергә карарын ныгытты.

* * *

Бер-ике көннән һәрнәрсә хәзерләнеп җитте. Тимергали кирәкле яшерен серләрне икешәр-өчәр нөсхәгә язып өлгерде. Яшерен планны икегә күчерде. Бөтен алай да баштан-аякка кадәр яшерен бер йипкә тезелде. Башында полковник, аннан соң өч-дүрт әфисәрдән бер комитә, аннан түбән алты-җиде унтер әфисәрләрдән бер комитә, аннан тубән алты-җиде гаскәрдән бер комитә. Шулар ашасыннан бөтен гаскәр бер әмер берлә бердән күтәрелеп, үзе теләгәнчә хәрәкәт итерлек хәлгә килде. Әфисәрләр берлә киңәшләшеп, китү планы тәмам хәзерләнде. Ул да бик садә иде: бер ике-өч көн алдан төрек команданына хәбәр жибәреләчәк, аннан хәбәр булгач, беркөнне полконникка штабтан ялган курьер киләчәк тә,

«һөжүм» дигән әмерне китерәчәк, полковник бөтен алайны үзе хәзерләгән юлдан алып китәчәк иде. Юлга чыгъш төрек фронтына якынлашкач та, комитә кешеләре рус әфисәрлерен тәүкыйф итәчәкләр. Полк, ак байрак күтәреп, Аксак Тимер маршын уйнап, төрек гаскәренә кушылачак вә кулындагы бөтен көчне төрекләр ихтыярына бирәчәк. Табигый, бу эш бик кыйммәтле сугыш серләрен ачып, иттифакчыларның бөтен планын аст-өст китерәчәк вә Төркияне һәлакәттән коткарачак иде. Моның өстенә Мирхәйдәр төрек команданын димләп, Төрек сугышының мәркәз сикълэтен төрек илләренә таба барырга, кирекмәгән гарәп йортлары өчен төрек каны түгүне туктатып, Кавказны, Төркстанны, Идел буен, Хәзәр диңгезен максат иттереп алдырырга иҗтиһат итeләчәк вә кулындагы мәгълүмәт, тәҗрибә берлә шул юлда хезмәт итeләчәк иде.

Алайның бөтен аңлы, иманлы забиты, аңлы гаскәре менә шул фикер берлә җанланган, менә шуны тизрек булдырыр өчен бөтен көче, куәте берлә аякка калыккан иде. Һәммәсе дә эш-эшкә җитмәевен элек мәйданга чыгып югалып калудан куркына, шуның өчен тиз-тиз хәрәкәт итәргә тырыша иде.

Менә беркөнне озын киңәштән соң, гади бер гаскәр тикшерелүе төсендә үз планнарының тәҗрибә маневры ясарга карар ителде. Полковник комитәгә үзенең бөтен актив көчләрен махсус план буенча төрле йирдә, төрле вазыйфалар башында булуга кушты. Вакыты җиткәч, үзе шуны тикшерергә чыкты. Әфисәрләрне үз урынында, унтер әфисәрләрне үз эше башында, гаскәрне кирәкле йирендә тапты. Кечкенә бер ишарә әмере берлә ут кебек хәракәткә хәзер булды. Лакин бер бүлекнең яшерен командиры йирендә Фәридәне күреп гажәпкә калды вә эшне бу кадәргә җибәрүгә сәбәп булуы өчен бик пошынды, тагы Арыслан Үлмәс угылынын гаиләсе, аларның киләчәк бәхетсезлекләре күз алдына килде. Ул бик тиз яшерен комитәне җыеп куркуын аңлатты, Фәридәнс өенә җибәрүнең лаземлеген сөйләде. Алар, әфисәрнең иң күбесе рус булынган бу бүлектә башка әфисәрне унтер юклыгын, гаскерләрнең бер авыздан Фәридәне сайлауларын сөйләделәр. Фәридәнең читкә калдырылуы гаскәрләр арасында аңлашылмау чыгуга сәбәп булмасын дип куркуларын бәян иттеләр. Ахырдан полковник мәсьәләне үзе хәл итәргә булды. Шул көнне үк өч кешедән төрек фронтына таба, Вахитның рәислеге астында, качкын һәйәте жибәрелде вә шул план анда кабул ителгәч тә, ул бер мәртәбә туп атып җавап бирелүе соралды. Бу тарафтан атылган өч туп — «көтәмез» мәгънәсендә, биш туп — «бик көтәмез», җиде туп — «көте-көтә актык чигенә җиттек» мәгънәсендә аңлашылырга тиеш, диелде вә өч көн эчендә бөтен мәсьәлә хәл ителергә сүз беркетелде. Һәйәт китте.

Полковник Сөемгә мәсьәләне аңлатмаган булганга, аңлатасы килмәгәнгә, Фәридәгә Сөемнән башка гына үзенә килергә хәбер җибәрде вә аны көтә-көтә эшендә дәвам итте. Менә төннең сонгы сәгатьләрендә генә Фәридә килеп кердс. Бик арыган булганга, тәкәлләфсез генә урынга утырды. Вак-төяк сүзләрдән соң полковник:

— Безнең Тифлистә сезнең берлә бер шартымыз бар иде, туташ, мин кайвакыт сезгә китәрге вакыт житте дисәм, сез китәргә сүз биргән идеңез. Хәзер менә шул көн җитте, сез иртәгә китергә тиешсеңез, югыйсә бөтен гаиләңезне бик авыр уңайсызлыкка төшерәчәксез вә минә дә гаиләңез алдында бик оятлы бер хәлгә куячаксыз. Сез инде иртәгә рәхим итеп кайтып китеңез. Кешегә белдермәс өчен бер телеграм килгән диярмез, — диде. Фәридә күптән мәгьлүм нәрсәне тыңлаган кебек иренеп кенә тыңлады да иренеп кенә җавап бирде. Эшне алай-болай үткәрмәкче булды. Тимергали үз фикерендә каты торганны күргәч:

— Мин, полковник, хәзер китә алмыйм. Узеңез күрдеңез, минем вазыйфам бар. Мин хәзер Арыслан кызы Фәридә генә түгел — сигезенче бүлекнең милли командиры. Шундый зур милли бурыч алдында торганда, мин вазыйфа башыннан китә алмыйм...

Полковник кызарды, бүртендс, шул катгый сөйләнгән сүзләргә җавап таба алмады. Ахырдан:

— Гаиләңез!..— диде.

Фәридә уйланды:

— Әйе, гаиләм кызганыч, бәлки анда аларга бик зур авырлыклар булыр. Ләкин бит болар һәммәсе — шундый коллыклар, рус ихтыярында уенчык булып яшәү бетсен өчен

эшләнә: алар аны аңларлар, гафу итәрләр. Бәйрәм корбансыз булмый, полковник... Без төреклек өчен бер бәйрәм ясарга хәзерленәмез — корбанымыз хәзер булырга тиеш. Безнең гаиләнең шул корбанны бирергә хәзерлеге җиткән. Төреклек өчен бер Арыслан угылы гаиләсе фида булса булсын! Мин үзем корбан булам икән, сөенеп булам. Мин китмим, полковник! - диде. Тимергалиненң иренен бик каты тешләп, тирәннән уйлаганын күреп: — Сез аңлаңыз, мин китә алмыйм... Китсәм, бу минем өчен бөтен гомеремә бер кара тап булачак. Бөтен гомеремә вөҗданым җәрәхәтле калачак... Шуның өчен ул вәгъдәләрне, полковник, хәтерләмәңез, мин китә алмыйм... Мин бит Тифлистә вакытта ук сезнек башта шундый бер план барын әллә ничек сизендем. Шуның өчен килергә омтылдым. Монда килгәч үземнән-үзем дә шул планны эшләргә керелттем. Сезнең колита эшләнеп беткәнчә, безнең бүлектә инде ул комитә бар иде... Мин инде аны ясаган идем. Сез кечкенә күнеллелек курсәтсәңез, мин сезгә тәэсир итәрга тырышачак идем. Менә ни өчен безнең бүлек мине командир итеп сайлаганнар... Хәзер эш үз юлын алды. Мин дә, полковник, шул эштә, хезмәтем аз булса да, сезнең юлдашыңыз булырга телим... Бу бит әле, полковник, безнең беренче адымымыз гына, без бит әле бу йирләргә милли байрак астында, һөҗүмче булып, тагы киләчәкбез. Без бит мондагы әрмәннәр, русларны себереп түгеп, Ганҗәсенә, Тифлисенә, Бакусына, бөтен Кавказга Төрек байрагы тегәчәкмез. Бу эшнең башында сезнең булуыңыз беренче шарт... Башка андый кешемез юк. Хәзер сезне саклау — милли бурыч. Бу эштә минем вазыйфам да бар, кирәгем дә юк түгел. — Бераз тыннан соң: — Полковник, мин хәзер гаскәриләрнең милли җанына юл булдым, бөтен уйларын, бөтен төшенчәләрен беләм. Алар бит бала... Күтәрелә китә, кызыша, яхшыны начардан аермый, вата, сындыра, кыра... Менә теге әрмән командирлары килгән көнне әфисәр клубына бомба ыргытырга хәзерләнгән булганнар. Алла гына сакчап калган... Әле мин килгәндә дә бер гөруһ сезне русчы дип үтерегә йөри иде. Мин генә арага кердем.

Пачковник ачыктан-ачык сөйләнгән бу сузләрдән, көтелмәгән вакыйгалардан аптырап калды. Бөтен дикькатене җыеп, аның һичбер хәрәкәтен югалтмас өчен күзен тегеп, аның хикәяләрен тыңлады. Үз-үзеннән: «Бу кем бу кыз? Бу куәт моңарга кайдан килгән? Бу яшьтә яшьлеген корбан итеп, ничек бу фикергә, бу гаягә капылган? Ничек үзен-үзе оныткан?» Сөальләренеә берсенә дә канәгатьләндерерлек җавап таба алмаса да, Фәридәнең зурлыгына, бөеклегенә күңеленнән баш иде. Аның һәртөрле корбанга хәзерлеге алдында күңелдән тез чүкте... Полковникнын башындагы шул уйларны сизенгән кебек, шуларга җавап биргән кебек, Фәридә батырланып сикереп торды, полковникның кулын килеп кысты. Акың зур дорфа кулларын үзенең нечкә, нәзек бармаклары арасыннан чыгармаенча, өмет ташкам күзен Тимергалинең күзенә батырды. Җавап ала алмагач, моң гына тавыш берлә: «Бетте бу киту сүзләре, полковник! Шулаймы? Бетсен!...» — диде. Аптырап калган полковникның кулын сыйпый-сыйпый башлады. Полковникның агарып килә торган чәчләре арасына бармакларын сукты. Мамык кебек бармаклары берлә аларны аралаштырды, сөиде, сыйпады... Тагы моңрак итеп: «Беттеме, полковник? Мин синең берлә калдыммы?» — диде. Аның күзеннән җавап котте. Фәридә, анда бетен теләгенә җавап булдымы, бөтен эчене пошырган эшләргә юл булдымы, бердән полковникның башын кочаклады, аны маңгаеннан, башыннан-битеннән убәргә тотынды. Үзе: «Мин китмим, мин китмим... Сез шундый авыр көннәр алдында булганда, мин китмим, аңлыймсыз? Китә алмыйм!» — диде. Күңеле тулды. Кычкырып еглап җибәрде. Аның бер күз яше тәгәрәп төшеп Тимергалинең маңгаена тамып, аның битен кытыкландырып йөзеннән акты. Үзеннән-үзе курыккан кебек, оялган кебек, Фәридә почмакка барып, посып еглавында дәвам итте.

Тимергали көтелмәгән бу вакыйгадан әлгәре каушады, аннан аптырады, ни эшләргә дә, нинди юл берлә дә хәрәкәт итәргә белмәде. Фәриднең үкереп-үкереп еглавы аның йөрәгенең әллә кай йирләрендә йөреп, аның астын өст итте. Уд үзенең полковниклыгын, бүген-иртәгә милләтенең тарихында һич онытылмаячак зур бер эш эшләргә хәзерләнүен онытты. Унҗиде яшьлек егет кебек Фәриднең янына чабып барды. Аның кулын алды, башын сыйпады. Фәридәнең муены көчсезләнгән, арыган кебек башын тота алмады. Ул

полковник иңсәсене егылды. Ефәк кебек куллары берлә анның иелми торгам муеннарына сарылды. Фәриданең калуы хәл ителде. Куркынычлы качу планнары аңарга полковник булганда һични түгел кебек куренде. Тимергалигә дә Фәридә кебек пакь, саф бер фәрештә янында торганда туп та, мылтык та берни түгел кебек хис ителде.

* * *

Хәбәрчеләр киткәннән ике көн вакыт үтте. Җавап тубы атылмады. Бу яктан өч туп атып сөаль бирелде. Хәбәр килмәде. Өч көм үтте — биш туп атылды. Җавап килмәде. Дуртенче көм булды, җавап килмәде. Җиде туп атылды — хәбәр килмәде. Яшерен комитә җыелды, тагы бер көн көтәргә карар ителде. Менә кич булды. Һәр кеше эч пошу берлә: тегеләр русларга төшмәдеме икән, сер ачылмадымы икән дигән куркулы уйлар берлә йокыга ятты. Полковник та пошынып, эш ачылмасын, бөтен план, бөтен эш юкка чыкмасын дигән уйлар берлә йокламаенча уйланып ятканда, ишек төбенә бик каты чабып килеп ат туктады. Полковник әллә ни чыкты, начар бернәрсә булды дип хис итеп, сикереп торды. Ишектән ук кебек атылып Фәридә килеп керде:

— Полковник, харап булдык, бөтен нәрсә беленде: капитан Иванов штаб берлә сөйләргә телефон сораган, тоташтыруда безнең кеше булган, шул тоташтырдым дип ялганлаган, үзе тыңларга тотынган да теге генералны чакырып, мондагы безнең бөтен хәлләр хакында хәбәр биргән. Тизрәк коралсызландыруның кирәклеген, рус әфисәрләренә башка, башкорт прапорщигы Атнагуловка гына ышанырга яравын сөйләгән. Генерал исеменнән бу да «Иртәгә телефон бирермен» дип сүзен кискән... Бүген китмәсек, һәрбер нәрсә ачыла!..

Полковник сөальле күз берлә Фәридәге карады. Фәридә:

— Төн караңгы, әле төн яртысы гына, бәлки утермез, диде. Полковник уйланды, уйланды, башыннан төрле планнар кичте. Ахырдан иптәшләре берлә сөйләшергә булды. Комитәне туплады. Кыска бер киңәштән соң хәрәкәткә, Ивановны юлда гына үтерергә карар ителде вә төн яртысында полковник җыелу боргысын уйнатты. Юл киемендә штабка барып, штаб начальниктан килгән ялган әмерне укыды. Күрше алайларга телефон берлә хәрәкәттән хәбәр ителде. Юл сакчыларына мәгълумат бирелде. Аерым бүлекләргә аерым юллар курсәтеп, төрек чигенең, теге ягындагы тау артында бергә тупланырга, мылтык атмаска, тавышланмаска боерды... Үзе бүлмәсенә килеп, яшерен серле кәгазьләрне берсен Фәридәгә бөти иттереп такты, берсен үзенә алды, берсе Ибраһимга яшерелде. Юлда андый-мондый эш булып, яңадан русларга төшеләчәк булса, бу кәгазьләрне юк итүнең, төрекләргә кайда төшелсә дә, иң башларына бирүнең тиешлеген аңлатты.

Бер сәгатьтән юлга чыгылды. Гаскәр атларына менеп, акрын гына хәрәкәт итте. Төн жилле, болытлы булганга, ул тавышсыз-тынсыз рус фронтын үтте. Менә юл ике тау арасына килеп керәчәк булды. Моның берсендә рус тупчылары йирләшкән кебек, икенчесенә төрек тупчыпары йирләшкән иде. Юлдан кемнең дә үтүе мөмкин түгел итеп туп, пулемет астына алынган иде. Полковник, мондагы русларга «Әмер алдым, кичәм», дип телефон берлә хәбәр биргәнгә, ул яктан курыкмый иде. Анның планы буенча теге өч кеше төрекләргә дә мәсьәләне аңлатканга, аннан да куркыныч булмаска тиеш иде, ләкин хәбәрнең килмәве анның планын бозган, аңарга сак булырга кушкан иде. Шуның өчен ул элгәре күрелмәгән кебек иттереп акрынлап үтәргә дигән карарны биргән иде. Ләкин тау янына килгәч булган вакыйга аны башкача хәрәкәт итерга кушты. Ул да бердән планын үзгәртергә мәҗбүр булды. Вакыйга моннан гыйбәрәт иде.

Кичүгә килеп җитәр алдында үз булегендә кичә торган прапорщик Атнагулов артта калып борылып чаба башлаган вә аньң артыннан киткан Иванов тотылып утерелса дә, Атнагулов куак арасына кереп югалган. Шул эштә берничә мылтык атылганга, тауның каравылчылары уянган, ике як та берәм-сәрәм мылтыклар атарга тотынган иде. Шуның өчен күренми кичу имкяны беткән, фәкать бик куркынычлы, тәһликале булса да чабып утәрге гена юл калган иде. Тимергали һар югалткан минут берничә җан торасын белгәнгә,

бердән чабып кичәргә әмер бирде. Ике-өч чакрым киңлектәге кичү ат берлә тулды. Гаскәр бөтен куате берлә чабып кичүгә керде. Әллә кайдан ай чыкты. Бөтен гаскәр ялтырап китте. Рус ягындамы, төрек ягындамы атылган туп гөрләп китте, гаскәрнең алдына төшеп ярылды. Аның артыннан беренче, икенче, өченчеләр атылды. Әллә кайдан пулемет җылтырарга керешә. Гаскәр һаман чапты, әллә кемнәр егылды, каны ага торган бер ат тиле кебек чапты, әллә кем ынгырашты, сыкранды, туп, пулемет тавышына ат гыжлавы, «Алга. алга!»— дигән командирларның тавышы катышты. Кичү кыяматка әверелде. Полковник Тимергали бер карады: янындагы гаскәренә, аның күршесендә кызы Сөембикәне күрде. Тагы бераз вакыт үтте: гаскәр йирендә күзләре кызарган Фаридәнс күрде. Тагы бер карады: алдына төшкән туп ядрәсеннән алдындагы саф ярылды, бер гаскәри мәтәлде, бер ат дүрт аягын күтәреп егылды. Аңарга әллә нәрсә тигән кебек булды. Күлмәге эченнән җылы бернарсә агарга тотынды. Ул атын сукты, алга чыкты. Бик зур тавыш берлә: «Алга!»— дип кычкырды. Бите канга буялган Фәридәнең куып житкәнен, кызы Сөембикәнен атыннан кан акканны күрде. Туп тавышланды, улады, гөрләде, пулемет туктамады — «мыж-мыж» итте, мылтык өзелмәде — шартлады. Атлы гаскәр рәтен югалтып, көтү кебек чапты, атлар исерек кебек дулады, яралылар ыңгыраштылар.

Мено кичү үтелде, гаскәр сәламәт йиргә чыгып житте, аның өстенә әллә кайдан прожектор төште: сөңгеләр, кылычлар, ызаннар ялтырап җавап бирде. Полковник гакылын югалткан кеше кебек: «Рәтләнеңез! Бүлеге бүлеккә!»—дип кычкырды. Бер минутта рәтләнделәр, бер минутта бүлеге бүлеккә аерылдылар... Ул эчендә ага торган җылы нәрсәләргә әһәмият бирмәенчә бөтен гаскәрне йөреп чыкты. Җәрәхәтләнгәннәр күп булса да, үлгәннәр бик аз иде. Командирларның күбе исән иде, сау иде... Яралыларны бәйләргә, җәрәхатлеләрне урынлаштырырга кушты. Ак баз багламнары берлә килеп җиткән Фәридәгә: «Минем жәрәхәтем кечкенә», —дип әһәмият бирмәенчә, гаскәрнең алдына чыгып канлы кулы берла ак байрак күтәрде. Шуның янына килеп житеп, Фәридә әллә кай бер йиренә яшерелеп куелган кызыл йирлектә төрек байрагы калдырды. «Яшәсен Төркия!» — дип кычкырып жибәрде һам гаскәр кычкырып жавап бирде. Төрек бүлегенең тубы туктады. Дошман гаскәре дип уйлап каршы чыккан төрек сәварие ни эшләргә белмәенчә аптырап калды. Менә бердән рус тавы гөрләде. Аннан берәмләп, күмәкләп туп атыла башлады. Тимергали: «Алга!»— дип әмер бирде. Атлы гаскар ук кебек алга чапты. Рус тубы, мылтыгы боларны Төркиянен эченә куды.

Менә таң атты. Туа торган яңы көннең моң яктысы ана йортка ашыга торган төрле кабиләдән җыелган төрек балаларын сәламләде, еракта түгел генә бернича манаралы бер кечкенә төрек шәһәре күренде. Полковник шунда юл тотты. Шәһәрнең алдына килеп басу берлә, гаскәрне тагы рәтләде, тагы бүлеген бүлеккә аерды. Музыкага хәзер булырга әмер бирде. Гаскәри тәртиптә шәһәргә керергә кушты. Үзенең каны берлә былчыранган аты шәһәрнең бусагасына басып өлгермәде, дурт-биш манарадан иртәнге азан башланды. Ихтыярсыз полковник атның тезгәнен тартты, әмергә өйрәнгән ат бердән туктады. Аның артыннан бөтеп алай туктады, хәттә эченнән ага торган кан да туктады. Азан бетте. Полковник: «Музыка!»— дип кычкырды. Аксак Тимер маршы гөрләде, шуңарга баса торган җиде-сигез мең атларның тавышы берлә шәһәр «ду» килде. Бу яңы музыкадан, яңы тавыштан бөтен шәһәр аякка калыкты. Төрек байраклы, рус киемле бу гаскәрдән һәммәсе, бердән, курыкты, икенчедән, аптырады, өченчедән, хәйран булды. Гаскәр киң урам буйлап акрынлап баруында дәвам итте... Аның бөтен атлавына урамнар, биналар сәлам биргән кебек тавышланып җавап бирде. Бөтен тәрәзәләргә халык тулды. Даирәләр, кышлалар аякка калыкты. Музыка туктар-туктамас гаскәрнең: «Яшәсен Төркия!» — дигән тавышы шәһәрне тотты...

Менә гаскәр шәһәрнең уртасына, әлгәреге бәладия даирәсе, хәзерге гаскәри штаб янына килеп бүлек-бүлек тезелде. Бинаның башындагы саллана торган төрек байрагы, озын юлдан килгән бу төрек угылларына жан күңелдән сәлам биргәп кебек, иртәнге йил берлә салланды, әллә ни сөйләгән кебек «фыр-фыр» килде. Вакыйгадан яңы гына хәбәрдар булган, аптырап калган төрек забитларының кышладан чыкканын күрү берлә, полковник:

«Сәлам тор!»— әмерен бирде. Унике кабилә угылларынын, сөңгеләре бердән күккә чыкты. Кунелләреннән иткән антларын Төрек байрагы «фыр-фыр» иттереп күкләргә кадәр күндерде, ләухелмәхфүзгә язарга кушты. Полковник Тимергали бер ягында кызы Сөем, бер ягында Фәридә, артында-алдында төрек эфисәрләре белә рус байрагын өстерәп килеп, сәлам тарызында торып алга чыкты:

— Без дә сезнең кебек төрек балалары. Төркиянең шул авыр көннәрендә, дошманнар берлә бөтен тарафыннан камалган көннәрендә, сезнең берлә бергә булып, ана йорт өчен үземезнең канымызны фида итәргә булып, рус сафын ташлап чыктык! Һәммәмезне кабул итеп, төреклек вазыйфамызны үтәргә әмер боеруңызны көтәмез!— диде, кулындагы рус байрагын забитларның аягы астына ташлады. «Яшәсен Төркия!»— дип кычкырды, гаскәр дә кычкырып җавап бирде.

Күзләреннән мөлдер-мөлдер аккан яшен тота алмаган төрек меңбашы полковник Тимергалине килеп кочаклады. Еллар буе күрешмәгән агасын-энесен көтелмәгәндә очраткан кебек, ул аны кукрәгенә кысты, башыннан үпте, битеннән үпте, тагы кочаклады, тагы үпте. Яшь мөлдерәп ага торган аның күзләренә шатлык, бәхет, көлемсерәү чыкты, күз яше берлә елмаю бергә кушылды. Аның артыннан бөтен забитлар килгән аркадашлары берлә күреште, үбеште. Төрек байрагын күтәреп тора торган Фәридә берлә Сөембикә генә каршылыксыз калды... Аларнын шул озын, ерак йирдән килүләрен котларга, аларның рус боендырыгы астында үткәргән шул озын газаплы көннәрен сорарга һәмширәләре, кардәшләре килмәде, аларга аналык, апалык, туганлык бүсәсен беркем дә бирмәде...

Менә бердән төрек музыкасы гөрләде. Ул Урда маршын уйнады. Аның артыннан меңбашы югары бер йиргә чыгып:

— Кардәшләр! Мин сезне һәммәңезне рус боендырыгыннан кортылуыңыз вә ана йортка ирешүеңез берлә котлыйм! Бөтен тарафтан дошман сарган бу йорт төрек иледер. Бу безнен ватанымыз булган кебек, сезнең дә туган йортыңыздыр. Безнең берлә бергә, безнең караңгы көннәремезне бүлешергә килгәнсез кардәшләремезгә безнең бәхетле көннәремездә дә илемез, йортымыз ачыктыр!..— Меңбашы сүзендә дәвам итә алмады. Сәлам тор тарызында баскан Мирхәйдәр калтыранды, селкенде, ул Фәридәнең өстенә ауды. Китерелган докторлар аның хушын китергәч та, Тимергали баш очындагы меңбашын күрер-күрмәс, үзенең күкрәгендәге хариталарын, яшерен гаскәри серләрне хәтерләде вә шуны алырга кулын сузды. Көчсез кулы шул эшне эшли алмаганны күргәч, ул күзе берлә Фәридәгә ишәрә итте. Фәридә шуларны алып меңбашына бирганче күзен кәгазьләрдән калдырмады. Фәридә: «Русия гаскәри штабының гизле серләре», — дигәч кенә Тимергали елмайды, Меңбашының шул кәгазьләрне ачканнарын караганда аның йөзеннән, күзеннән елмаюы китмәде. Шул — милләтемне сакладым кәефеннән чыккан көлү, елмаю аның рухын күкләрга кадор озатты — елмаеп җаны чыкты.

* * *

Бөек бер хөрмәт берлә полковник күмелде. Аның баһадир гаскәре инглизләргә каршы барып, аларны әсир алышты. Аның китергән гизле серләре рус иттифакчыларының сугыш серләрен ачып, планнарын боздырды.

Төркия хөкумәте тарафыннан Сөембико Истанбулга алдырылды вә бер мәктапкә йирләштерелде. Фәридә генә җәбһәне ташламады, ул һәмширә булып сугыш сафында калды. Киләчәк форсатта: Батумга, Ганҗәгә, Бакуга төрек байрагын алландыру, Төркстанга, Кырымга, Идел—Уралга Алтын Урда байрагын салландыру көнен көтеп калды. Шул татлы көнгә хәзерләнер өчен гаскәрләр арасында фикердәшләр, иптәшләр, аркадашлар туплавында дәвам итте. Туган көннед һәрберсендә, ул шул өметнең, тагы бер көн якынлавына ышанып, тыныч-тыныч көнне төнгә кушты. Ирешәчәгенә иткән имам

берлә айлар, елларны сафта үткәрде. Бәхетле кортылыш көнен бәкләде.

## Искәрмәләр һәм аңлатмалар:

Җәбһә – фронт

Гаскәрчә – хәрбиләрчә

Харита – карта

Ишарәт – билге, тамга

Морад чае – Морад елгасы

Форат – Ефрат клгасы

Дәҗлә – Тигр елгасы

Саллану – чайкалу
Шәфкать һәмширәле – Шәфкать туташлары

Анатули – Кече Азия

Иран төоке – азәрбайҗаннар

Балалар тегермәне – әйләнә торган уенчык

Җәнүб – көньяк

Алай – гаскәр

Төшенү – уйлау

Каналҗя царица – мәлгун ханша (Г.Исхакый искәртмәсе)

Мәгаш – акча

Гөрҗи – грузин

Фандык (фундук) – эре чикләвеге

Вон, вон, вон! – урысча куып чыгару сүзләре (Г.Исхакый искәртмәсе)

Манзарә – күренеш

* Руслар күп вакытта бөтен Русия мөселманнарына “татар” исеме кулланалар. Азәри тйрекләренә дә күп вакыт “Баку татарлары” тәъбире йөртәләр (Г.Исхакый искәртмәсе)

Мөзакәрә – фикер алышу, сөйләшү

Комита

Комитет

Җасуслык – шымчылык

Кәһвә – кофе

гая – теләк, идея

Мәд – сузу билгесе

Хилаф – каршы

Дарелфөнүн – университет

Кул урду – гаскәр бүлеге

Мәгаш – яшәү өчен кирәк әйбер

Тәвәккый – туктату,тыю

Дөхан – кибет

Мөрәккәб – җыелган

Имкян – мөмкинлек

Тәүкыйф итү – тоткын итү, кулга алу

Инкыйлаб – бу урында: түнтәленеш, переворот

Сәфаләт – бозыклык

Мивә – җимеш

Забит – офиөер

Күрфәз – култык

Әвәт – әйе

Әман – зинһар

Дуйорләр – кыйныйлар

Иштә утуртийорләр арабия, гитрийорләр, соңра гидийорез, һәркөн буйлә, беремез хаста дүшде – менә шулай автомобильгә утырып алып киләләр, бераздан китәбез, һәр көн шулай, беребез авырый башлады.

Орду – гаскәр
Инкыйлаб – революөия

Кыйсем – бу урында: төркем

Тишелеп – чишелеп

Явер – ярдәмче, адъютант

Харита – карта

Иттифаккчы – союзник

Әркяне хәрбия – хәрби штаб, хәрби командалык

Мәсафә – мке урын арасындагы ераклык

Ингелтерә – Англия

Хәзәр диңгезе – Каспий диңгезе

Ихтилял – фетнә, бунт, революөия

Химая - яклау.

Рәкыйб - көндәш.

Тиҗарәт - сәүдә.

мәгълүб- җиңелү.

Истикълял - бәйсезлек.

Хәйрәт - аптырау.

Чанта - сумка.

Олрайт (инглизчә) - бик яхшы.

Куланил - полковник.

Күңелле гаскәр- ирекле гаскәр.

Жәзаир - Алжир.

Фәс - Морокко.

Кәнҗ - яшь, яңа.
Мөзакәрә - сөйләшө, фикер алышу.

Лазем - тиеш.

Жәбһә- фронт.

Рәкым - сан, цифр.

Иттифак - берлек, союз.

Тәфсыйлат - җентекләү.

Мәгърузә - доклад.
Минтака - жир шарының климат поясы.

Могаһәдә- килешү, сүз бирешү.

Тәфсир итү - аңлату.

Гаид түгел - карамау, кагылмау.

Жаһил - надан.

Сәләхият - мөмкинлек.

Тәгайен ителү - билгеләнү.

Мотлакан - ничек булса да.

Парис – Париж

Тәкъсим – бүлү

Бизанес – Бизантия

Салиб – хач, тәре

Виф ля рус, виф ля имперер – яшәсен рус, яшәсен император

Һәяҗан – дулкынлану, аптырау

Кятиб – секретарь

Урду (орду) – гаскәр

Чалынды – бу урында: уйналды

Икърар – тану, ышану

Сукты - бу урында: кертте.

Җәрәян компания.

Шигар өндәү, лозунг.

Мөнәүвәр бу урында: аңлылар.

Манигъ - киртә.

Мөстәгъҗәл - ашыгыч.

Иттифакый – очраклы

Гаскәр – солдат

Түрән – поезд

Мәсъүлият – җаваплылык

Гая – теләк

Мөддәт – вакыт аралыгы

Забит – офиөер

Алай – гаскәр

Гизле – яшерен

Тәшктләт – оешма, оешканлык

гасаби – тиз кызучан, нервный

Комитә – комитет

Әркәне хәреб забитлары – хәрби штаб офиөерлары

Истыйлях – атама, термин

Мәгърүзә – доклад

Фамилия – гаилә, нәсел

Гаскәрлек – солдатлык

Әһле салиб сугышы – тәре сугышы
Әлгаязе биллаһ – Аллаһ сакласын

Истигъфа итү – хезмәттән азат ителү, отставка

Чзверү – эйләндерү

Лижиюн дуаунур – почетлы легион

Зыяфәт – кунак итү, сыйлау

Муаффәкыять – уңыш

Тәэкид итү – раслау

Сөзү – текәлеп карау

Патлау – шартлау, кабынып китү

кышла – лагерь

Күтәрмә – кутерьма

Җиберләнеп – ясалмаланып

Тәүкыйф итү – кулга алу

Иттифаккчы – союзник

Мәркәз сикъләт – төп йөге

Һәйәт – бу урында: делегаөия, төркем

гөруһ – төркем

Гая- ният, идея

Имкян – мөмкинлек

Тәһликә – һәлакәт

Сәвари – атлы гаскәр

Бәладия даирәсе – шәһәр идарәсе йорты

Каршылыксыз калды – каршылаучылар булмады

Һәмширә – бу урында: апа, сеңел

Бүсә – үбешү, туганлык күрсәтү

Тарызында – рәвешендә

Кортылыш – котылу

Бәкләде – көтте

**Өйгә таба.** Повесть Берлинда 1922 елда языла. 1938 елда Берлиндә үк «Милли юл» нәшриятендә гарәп имлясында «Мө- хәммәдгаяз Исхакый» имзасы белән басылып чыга. 88 бит. Китап гадәти зурлыкта, кәгазь тышлыкта. Алгы тышлыкның эчке ягында мондый сүзләр язылган: «Бу әсәр «Милли юл»ның үз матбагасында хәреф тезү машинасы берлә тезелде».

Арткы тышлыкның эчке ягында «Милли матбугатны укы- гыз!» дигән баш астында «Милли юл» мәҗмугасы һәм «Милли байрак» гәзитәсенә рекламалар бирелгән: «Милли юл» «Идел- Урал» истикълял фикерен таратучы айлык мәҗмугадыр. Бик күп авырлыклар эчендә тукыз елдан бирле үзенең юлын какшатмыйча алып килә торган мәҗмугамызга матди һәм мәгънәви ярдәмдә булу һәр милләттәшнең вазыйфасыдыр. Язылу бәһасе: бер елга - өч ярым, ярты елга - ике америка доллары. Адрес: Redaktion «Yana milli yul», Berlin-Charlottenburg 1, Postfach Nr.8 (Germany)»; «Милли байрак» гәзитәсе бик бай эчтәлек берлә һәр атна монтазам рәвештә ике елдан бирле чыгып торадыр. Бу Ерак Шәрекътагы бердәнбер милли матбугатымыз, һәр төрле бик кыйммәтле вә файдалы язулар берлә бергә Ерак Шәрекъ милләттәшләремезнең милли тор- мышлары берлә дә таныштырып киләдер. «Милли байрак»ның дәвамы вә аның таралуы ялгыз мөһаҗирлек тормышымызның мәгънәләнүе генә түгел, бөтен милли барлыгымызның куәтләнүе димәктер. Абүнә бәһасе: бер елга 7 йен. ярты елга 4 йен. (Сорату адресы: The milli Bairak, nip. PO. Box 104, Mukden (Manchuo-Tikuo).

Шул рәвештә алга таба да Г. Исхакыйның «Милли юл» нәшриятендә чыккан һәр китабында мәҗмугага һәм гәзитәгә реклама язылып барыла. Шул ук вакытта «Яңа милли юл»да һәм «Милли байрак»та язучының Берлинда басылып чыккан һәр китабына байтак саннарда реклама бирелә һәм шул ки- таплар турында укучылар фикере дә басылып килә.

Язучы әсәрен «хикәя» дип атаган.

Бу китап Исхакыйның мәгълүм «Васыяте» белән бергә байтак еллар Казанда республикабыз җитәкчеләре сейфында ятканлыгы билгеле. Аны озак өйрәнгәннәр, типшергәннәр. Бу хакта сүз халык арасына да чыккан. Сиксәненче елларның башында ук ара-тирә: «Гаяз Исхакыйның туган илне сагыну хисләре белән сугарылган «Өйгә таба» дигән әсәре бар икән»,-- дип ишетелгәли иде.

1987 елда, инде руслар бик күп эмигрант язучыларының әсәрләрен хәзерге укучыга кайтаргач та, әдипнең үзен һәм аның «Өйгә таба» повестен «фаш итеп» язылган «На свалке истории» исемендәге мәкалә чыкты. («Слово агитатора» журналы, Казан, 1987, 13 нче сан. ) Әмма бу повесть, имеш-мимешләрдә әйтелгәнчә, туган илне сагыну турындагы әсәр дә түгел, әлеге мәкаләдән аңлашылганча, эмигрантлар арасында контрре- волюцион идеяләр тарату өчен язылган әйбер дә түгел. Г. Исхакый бу әсәрен чит илгә чыгып киткәнче үк язарга планлаштырган булган. Моңа дәлилне язучының 1915 елда басылган «Остазбикә» исемле әсәренең титул битендә табарга мөмкин. Анда авторның 8 җилдтән торган «Мәжмугаи асар»ендә басылган һәм басылачак китаплары исемлеге бирелгән. 8 нче жилднең 3 нче китабы итеп «Өйгә таба» күрсәтелгән. Әмма автор ул чакта әсәрен язып өлгерә алмаган булса кирәк, 1918 елда 8 ул нче җилднең 3 нче китабы булып аның «Ул әле өйләнмәгән иде» хикәясе басылган.

Г. Исхакый Пинегадан сөргеннән качкач, 1908, 1911 ел- ларда, Төркиядә дә яши. «Өйгә таба» әсәрен язу теләге дә, бәлки, шул елларда тугандыр. Шул чорда сугыш турында материал да туплаган булырга мөмкин.

Повесть шулай ук Берлинда чыгып килгән «Татар легио- нының атналык гәҗите» булган «Идел-Урал»да 1943 елның 31 октябреннән 1944 елның 13 февраленә кадәр (барлыгы 12 санда) латин имлясында дөнья күрә.

«Өйгә таба» әсәрен Г. Исхакый үз тәрҗемәсендә төрек телендә «Eve dogru» исемендә Истанбулда 1941 елда латин имлясында бастырып чыгара. 125 бит. «Өйгә таба» әсәрем» дигән кереш мәкаләсендә ул болай яза: «Бөтендөнья сугышы вакытында Рәсәй ягында сугышкан Идел-Урал яшьләре, алман- нарга әсир төшкәннән соң, асылларын, төрки булуларын аңлап, Төркиягә үз ирекләре белән күченәләр һәм Төрек гаскәре сафларында Багдад фронтында батырларча шәһид булалар. «Өйгә таба» дип исемләнгән бу китабым алар рухына багышлана. Мин аны 1922 елда Берлинда шимал төрекләре телендә яздым. Һәм ул басылып чыкты. 1927 елда әсәрем төрек теленә тәрҗемә ителеп** «Төрек Учаклары» нәшриятенең планына кертелгән иде, ләкин бастырылмый калда, тәрҗемә дә югалды.

Кайбер милләтче төрек дусларымның үтенече буенча мин китабымны кабат төрекчәгә тәрҗемә иттем һәм менә хәзер төрек китап укучыларына тәкъдим итәм. Исемне үзгәртми калдырдым. Чөнки, минемчә, төрле төрки илләрне рухи яктан берләштерүгә иң көчле символ-төрки өй, ягъни традицион төрки гаилә тормышы.

Ерак Идел ярларыннан, Урал тауларыннан килгән яшьләр, Төркия өчен сугышып, нәкъ менә шул «ана өен», төркилекне саклап калу хакына җаннарын фида иттеләр. Әгәр бу әсәрем Төркия төркиләренең кечкенә бер өлешен булса да башка илләрдәге төркиләрнең яшәү рәвеше, фикерләре, кайгы һәм борчулары белән азмы-күпме таныштыра алса, хезмәтем бушка китмәде, төркилек идеясе алдындагы бурычларымның меңнән * берсен үтәү бәхетенә ирештем дип әйтә алачакмын».

Мукденда чыгып килгән «Милли байрак» гәзитәсе болай яза: «Бөек милли җитәкчебезнең бу «Өйгә таба» исемле әсәре гәзитәбезнең 1938 ел, 146 нчы санында язылган тикшермәдән (бу санны күрә алмадык Л.Г.) һәм китап сөючеләр кулына таралган нөсхәләреннән Ерак Шәрекътагы халкыбызга якыннан таныш булганга, «Өйгә таба»дагы мәшһүр әдипнең оста каләме белән күзгеләндерелгән вакыйгаларга тукталмыйбыз. Идарәбезгә 20 нче апрельдә килеп җиткән «Eve dogru» башлыгы белән 125 битле, уртадан кечерәк кулда басылган бу китап төрекчелек мәхәббәтене тагын да жанландыра, Төркиядән кардәшлек сәламе китерә төсле булды. Хөрмәтле милли җитәкчемез һәм бөек әдибемез Гаяз Исхакый жәнабләрен төрекчелек хислә- ребезне һәм кайда аңлап, кайда аңламый дошман сәясәте балта- сына саф булып йөрегәннәребезнең хезмәтләренә булган җирә- нечебезне бу бөек әсәрендә күңелнең иң тирән катлауларына барып җитәрлек рәвештә жанлы итеп тасвир кылуы өчен яңадан рәхмәт укыйбыз.

Төрек кардәшләребез, Идел буе төрекләренең милли дәрте белән сугарылган бу китапны укып, төрек берлеге әмәлене әдәбият аркылы куәтләндерү [не күрерләр]» (1941, 25 апрель, 259 сан).

Төрек телендәге «Өйгә таба» 1967 елда Истанбулда Өтүкән (Ötüken) нәшриятендә кабат басыла: «Роман. Икенче баскы». 120 бит. Редакциядән язылган «Берничә сүз»нең тәрҗемәсе: «Мөхәммәд Гаяз Исхакый әдиптән бигрәк бөек идеал иясе булып хәтерләрдә калган. Шул бөек идеалына тормышын да, каләмен дә багышлады. Ул төрле жанрларда язды. Матур әдәбиятта, аеруча, роман жанрында шөһрәт казанды. Соңга таба сәнгатьчәлек - әсәрләрен язу өчен үтемле чара булудан да узып, аның аерылмас шәхси сыйфа әйләнгән иде. Күңеле еламаганның күзе еламый, диләр… Бүленеп төрле төрки илләрнең иректән мәхрүм булуы Гаяз Исхакыйны ифрат борчыган. Бөтен төрки халыкларны әсирлек зинданыннан азат итеп, соңыннан Көнчыгыш Аурупадан алып Урта Азиягә кадәр сузылачак Бөек төрки берлеген төзү идеясе аның фикри, гамәли һәм ижади эшчәнлегенең нигезен тәшкил итте. Ул шул идеянең утында янып, аннан илһам алып бу әсәрен ижат итте.

Без «Өйгә таба» әсәрен бастырып, бөек язучының исемен оныттырмау, төрле фикер агымнары арасында үзләренә дөрес юл табарга тырышкан яшь буынның фикер вә күңел баскычына Мөхәммәд Гаяз Исхакый идеяләренең берничә булса да орлыгын чәчү максатыннан чыгабыз. Чөнки йөзьяшәр чинар агачы хәятенең сере дә әнә шул кеп-кечкенә орлыкларда саклана».

«Өйгә таба» повесте 1998 елда Истанбулда өченче тапкыр төрек телендә нәшер ителде. Өтүкән нәшрияты. 117 бит.

Бу повесть - Г. Исхакыйның төрек телендә китап булып басылып чыккан бердәнбер әсәре. Төркия китапханәләрендә китаплар күптән инде компьютерларга салынган. Анда Г. Исхакыйның нибары әнә шул төрекчәгә тәрҗемә ителгән «Өйтә таба» повестын гына күрергә мөмкин. Китапханәчеләрнең әйтүенчә, язучының татарча фондларда булган очракта да, «госманлыча» (ягъни гарәп имлясында) язылганга күрә, компьютерда урын алмаган. Әдипнең «Мили юл» («Яңа милли юл») исемле журналлары белән дә шундай ук хәлне күрәбез.

«Өйгә таба» повесте Төркиядә «Дөнья әдәбияте» дигән баш астында лицейлар, югары уку йортлары программасына кертелгән. Төрек уку йортларында белем алучы яшьләр, шушы әсәрне өйрәнеп, татарда Гаяз Исхакый дигән язучы барлыгын белеп калалар.

Текст 1938 елгы басмадан алынды.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 5 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 2009. Б. 19-87
Текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче
**Гайнанова** Лена Рәшит кызы